УРАК ӨСТЕ

«ВТ» хәбәрчеләре Аксубайда комбайнчыларның хәлен белеште

> 5

СӨТ БӘЯСЕНЕҢ

кинәт төшү сәбәбе нидә?

> 7

ФИРДҮС ГЫЙМАЛТДИНОВ:

«Яздырылган тавышымны тыңларга яратмыйм»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҗТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 116 (28889) | Җомга | 12 август | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

ХОЛЫКСЫЗ ҖӘЙ

ЧӘЧӘКЛЕ, ҖИЛӘКЛЕ АЙЛАРНЫҢ ХӘВЕФ-ХӘТӘРЕ ДӘ АЗ БУЛМАДЫ

Эссе үзенекен итә. Коену сезоны башланганнан бирле республикада 39 кеше суга батып үлгән, яшен сугу нәтиҗәсендә 28 янгын чыккан... Чагыштыру өчен: узган ел яшен сугу нәтиҗәсендә ел дәвамында 22 янгын булган. Көн дә бер афәт. Рәхәтлек белән бергә михнәте дә сагалый. Җәй, тынычлан, диясе килә кайвакыт...

> 6–7

Ишетми калмагыз

Сентябрь аенда Татарстанда яңа оешма – Дәүләт юридик бюросы эшли башлый. Премьер-министр Алексей Песошин бу җәһәттән тиешле карарга кул куйды.

Мондый бюро булдыру – Юстиция министрлыгы тәкъдиме. Бюро халыкка бушлай юридик ярдәм күрсәтәчәк. Штатта хезмәткәрләр саны уннан артмаячак. Исегезгә төшерәбез: яңа оешма булдыру турында закон проектын депутатлар Дәүләт Советының егерме тугызынчы утырышында хуплады. Юстиция министры Рөстәм Заһидуллин әйтүенчә, Россиянең инде 28 төбәгендә шундый оешма эшләп килә.

Татарстан җире, Оренбург өлкәсе аша узучы чиккә төгәллек кертелгәннән соң, берникадәр зурайган. Росреестрның республика буенча идарәсе матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына (ЕГРН) Татарстан белән Оренбург өлкәсе арасындагы чик турында мәгълүматлар кертелгән. Чикнең гомуми озынлыгы 195 чакрым тәшкил итә. Ул урманнар, сулыклар һәм өлешчә кырлар аша уза. Мәгълүматлар ачыкланганнан соң Татарстан территориясе берникадәр арткан. Чикләрне билгеләү архив, ЕГРН мәгълүматлары, 1990 нчы еллардагы картографик материаллар һәм җирлекләрнең 2008–2019 еллардагы фотопланнары нигезендә хәл ителгән. Шулай ук ике төбәктә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләре дә игътибарга алынган.

Яшел Үзән районында мошенниклар өч пенсионерны алдаган. Эчке эшләр министрлыгы хәбәренә караганда, өлкән яшьтәге ханымнарга китерелгән гомуми зыян күләме 975 мең сум тәшкил итә. Кырыгалдарлар, гадәттәгечә, «туганыгыз юл һәлакәтенә юлыккан, аңа ярдәм кирәк» дигән булып, тегеләрдән акча каерган. Шулай итеп, 1933, 1936 һәм 1942 елгы әбиләр мошенникларга курьер аша үзләренең хәләл акчасын биреп җибәргән.

Татарстанда беренче яртыеллыкта сатылган хәмер күләме узган елның шушы ук чорындагыга караганда 6 процентка артып, 2,75 миллион декалитр күрсәткеченә җиткән. Узган елның гыйнвар – июнь чорында ул 2,61 миллион декалитр күләмендә сатылган булган. Белгечләр әйтүенчә, быелгы күрсәткеч – рекордлы, чөнки соңгы елларда бездә спиртлы эчемлекләр сатуның кимүе күзәтелгән. 2015 елда иң аз күләмдә (2,57 миллион декалитр) сатылган.

Хәтерләсәгез, хөкүмәттәгеләр, халык контрафакт куллануга күчә, дип, хәмернең аз сатылуына берничә тапкыр борчылу белдергән иде. Вице-премьер Рөстәм Нигъмәтуллин, килеп туган хәлнең сәбәбе – авылларда кибетләрнең кимүе, дип тә аңлатты. Федераль һәм төбәкләрнең хәмер базарларын өйрәнү үзәге директоры Вадим Дробиз әйтүенчә, хәмер кулланунын артуы иң элек дөньяның тыныч булмавына бәйле. Кешеләр тынычлану өчен «салгалый». «Әмма 6 процентка арту – «нормаль» арту. Кемдер көненә 100 грамм эчкән булса, хәзер 106 грамм «тотып» куя икән, моның берниндә дә куркынычы юк», – дигән ул.

Районнарда ни хәлләр?

Яшел Үзән

Районның иң өлкән кешесе Әминә Гыйльманова 106 яшьлеген билгеләп үтте. Әбине күркәм юбилее белән район башлыгы Михаил Афанасьев исеменнән аның урынбасары Николай Бызин котлады. Әминә Гыйльманова Олы Шырдан авылында 10 бала тәрбияләнгән гаиләдә туа. Мәктәптә укымый диярлек, чөнки гаиләсенә ярдәм итү өчен эшләргә кирәк була. 1930–1947 елларда колхозда сыер савучы, урман посадкаларында, аннан соң Казан тимер юлында йөк төяүче булып эшли. Ә соңрак, 21 ел дәвамында Яшел Үзәннең Серго исемендәге заводының химия җитештерү цехында эшләп, аннан лаеклы ялга чыга. Бүген исә Әминә апа кызы Мәдинә тәрбиясендә матур картлык кичерә.
(«Яшел Үзән»)

Кукмара

Районда «V Мәчкәрә укулары» дип исемләнгән Россиякүләм фәнни-гамәли конференция узачак. Әлеге чара Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан Татарстанның Кукмара мөхтәсибәте тарафыннан данлыклы Мәчкәрә авылында уза. Революциягә кадәр ул Россиядә иң зур мөселман мәгарифе учакларының берсе булган. Мәчкәрә тарихы 1678 елдан ук билгеле. 1791–1793 елларда бирердә I гильдия сәүдәгәре Габдулла Үтәмешов акчасына таш мәчет салына. Бүген ул Татарстан җирлегендә Екатерина II указыннан соң салынган иң борынгы таш мәчетләрнең берсе санала. Хәзер бирердә реставрация эшләре бара.
(Татарстанның Диния нәзарәте)

Бөгелмә

Бөгелмә районы Карабаш бистәсендә герой-шагыйрь Муса Җәлилнең кызы Чулпан Җәлилова кунак булды. Очрашуны туган якны өйрәнүче, Карабашта туган журналист Фазыл Вәлиәхмәтов һәм Казандагы Муса Җәлил музее вәкилләре оештырды. Чулпан Җәлилова Карабашта герой-җәлилчеләр һәйкәленә чәчәкләр салды. Ул бирердә имән үсентеләре утыртты. Карабаш – шагыйрьнең көрәштәше Гәрәф Фәхретдиннең туган ягы. Сугыштан соң ул шагыйрьнең әсирлектә алып барган эшчәнлеге турында китап язган. Әлмәт драма театры бу әсәр буенча спектакль куйды, ул Карабаш мәдәният йорты сәхнәсендә Җәлилнең кызы килгән көнне күрсәтелде.
(«Лениногорск хәбәрләре»)

Мамадыш

Соколкада конфессияара үзәк эшли башлады. Анда православие һәм мөселман диннәрендә булган яшьләр бергәләп экскурсияләргә йөриячәкләр, мәдәни чараларда катнашачаклар. Программалар намаз, кичке дога кылу вакытларын исәпкә алып төзелгән. Үзәк 10 көн эшләячәк. Яшүсмерләр Кирмәнчек шәһәрчегендә, «Изге касә» комплексында булачаклар; борынгы чиркәүләрне һәм мәчетләрне караячаклар; Болгарга, Казанга, Алабугага һәм башка истәлекле урыннарга сәфәр кылачаклар.
(«Нократ»)

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның республика районнарына эш сәфәрләре башланып китте.

Апас. Районда Рөстәм Миңнеханов урып-җыю, крестьян-фермер хуҗалыгы эшләре белән танышты.

Район башлыгы Айрат Җиһаншин хәбәр иткәнчә, игенчеләрнең барлыгы 70 мең гектардан уңыш җыеп аласы бар. Мәйданның чирегендә эшләр инде тәмамланган. Кыр уңганнары һәр гектардан уртача 35,6 центнер уңыш җыя.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Рөстәм Миңнеханов районда терлекчелек юнәлешендә эшне көчәйтергә кирәк дип белдерде. Хәзерге күрсәткечләр белән генә канәгать калырга ярамый. «Бөтен проблема терлек азыгы белән тәэмин итүдә. Терлек азыгы булса, сыерлар асрарга теләүчеләр күбрәк булачак. Димәк, сыйфатлы сөт булачак. Моннан тыш, сөт сату – авылда тотрыклы хезмәт хакының чыганагы. Әлбәттә, аны сата алачагыңа ышаныч та булырга тиеш», – диде Президент.

Эш сәфәре кысасында Президентка Ибраһимов крестьян-фермер хуҗалыгының сөт-товар җитештерү фермасын күрсәттеләр. Бирердә 300ләп баш мөгезле эре терлек асрыйлар. Тагын 400 башка исәпләнгән ферма төзелә.

Буа. Татарстан Президенты Буада да урып-җыю эшләре белән танышты. Район башлыгы хәбәр иткәнчә, бөртекле культуралар өчен 54 мең гектар мәйданның 33 проценты урып-җыелган. Барлыгы 210–220 мең тонна уңыш җыеп алу көтелә.

Моннан тыш район сөтчелек буенча да яхшы күрсәткечләргә ия. Буада тәүлегенә 133 тонна сөт җитештерәләр. Шуның 36 тоннасын халыктан җыялар. «Терлекчелек буенча мөмкинлекләрегез зур. Азык үзәкләре ясарга кирәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Моннан тыш Президент Буа медицина училищесы бинасын төзекләндерү, яңа парк төзелеше эшләре белән танышты.

(Теманың дәвамы 5 нче биттә)

ИЛ КҮРКЕ

ТАТАРСТАНГА РОССИЯ ГЕРОЙЛАРЫ КАЙТТЫ

Шушы көннәрдә Казан танк училищесын тәмамлаган ике якташыбыз Россия оборона министры Сергей Шойгу кулыннан «Россия Герое» дигән мактаулы исемне алды. Аларга бу бүләкне махсус хәрби операция барышында күрсәткән батырлыклары өчен тапшырдылар. Геройларны Татарстан Президенты да котлады.

Питрәч егете Иван Додосов (сулда) һәм Әлки районыннан Раил Габдрахмановны тантаналы шартларда Казан аэропортында каршы алдылар. Очрашуга гаиләләре, дус-ишләре, республика җитәкчелеге дә килгән иде. Егетләрнең икесе дә Украинадагы махсус хәрби операциядә катнашып, батырлык күрсәткән.

Иван Додосов кечкенәдән хәрби булырга хыялланган. Хәзер ул – танк батальоны командиры. Россия Герое да! Казан танк училищесын тәмамлаган егет берничә елдан шундый исемгә лаек булырмын дип башына да китермәгәндер. Самолеттан төшүгә аны гаиләсе, балалары, туганнары урап алды. Барысы да Иванның исән-сау кайтуына сөенеп туя алмый.

– Болай бәйрәм ясап каршы алулары гаҗәпләндерде. Хисләр ташый. Бер сүз белән генә аңлатып та булмый. Мактаулы исем өчен горурлык хисләре дә кичерәм, – ди ул.

Әнисе Татьяна да улының күркәм сыйфатлары турында сөйләп туя алмый. «Кечкенә чакта, галстук киям, җитәкче булам, дип хыяллана иде. Ул бик гадел, намуслы һәм мәрхәмәтле. Кеше аркасына ышыкланып утыра торган түгел. Ул гел алга барачак», – ди ул.

Россия Герое Раил Габдрахмановка туган ягына туган көнендә кайтырга насыйп иткән. Ике көн элек 33 яшен тутырды ул. Кылган батырлыгы турында тыйнак кына:

– Бу – батырлык түгел, эшебез шул, – ди.

Раил дә Казан танк училищесын тәмамлаган. Новосибирск, Кемерово өлкәсе, Алтай краенда хәрби хезмәттә булган. 2022 елның февраленнән исә – Украинада.

Раилнең батырлыгы турында күпләр ишеткәндер. Аның җитәкчелегендәге танк ротасы дошманның оборона чиген өзгән һәм торак пунктны азат иткән. Ә офицер үзе биш дошман танкын юк иткән.

Егетләрне якыннары янында ял көтә. Аннан исә янә Ватанга хезмәткә.

Күгебез тыныч булсын!

12 август – Хәрби-һава көчләре көне. Татарстан Премьер-министрының беренче урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин хәрби авиаторларны һәм Хәрби-һава көчләре ветераннарын һөнәри бәйрәмнәре белән котлады.

«Бу бәйрәм күп еллар дәвамында Ватаныбызга каһарманнарча хезмәт итү һәм хәрби бурычны фидакарьләрчә үтәү символы булып тора, – диелгән котлауда. – Авиация элек-электән Россия Кораллы Көчләренең иң җитез, иң җәһәт төре буларак, илебезнең иминлеген, һава киңлекләрендәге мәнфәгатьләрен лаеклы төстә саклап килә.

Бөек Ватан сугышы елларында хәрби очучыларның каһарманлыклары, авиация сәнәгате хезмәткәрләренең фидакарьлеге Россия елъязмасына алтын хәрефләр белән уелып язылган. Хәрби авиация тарихы бөек Ватаныбызның данлыклы узганы белән аерылгысыз бәйле.

Бүгенге хәрби очучылар һәм штурманнар, авиация белгечләре Россия армиясенең иң яхшы традицияләрен дәвам итүчеләр, лаеклы варислар булып тора. Алар үзләренең хәрби бурычын намус белән үти, илебезнең иминлеген, дәүләт мәнфәгатьләрен саклау, халыкара терроршылыкка каршы көрәшү буенча фидакарьләрчә хезмәт итә.

Россиянең хәрби авиациясен үстерү һәм камилләштерүгә авиатөзелеш предприятиеләренең меңнәрчә хезмәткәре гаять зур өлеш кертеп килә.

Республикада яшәүчеләрнең барчасын Хәрби-һава көчләре көне белән котлыйм! Иминлек, нык сәламәтлек, Россия файдасына хезмәттә алга таба да уңышлар телим!»

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Россия Герое» исеменә лаек булган майор Иван Додосов һәм майор Раил Габдрахмановка котлау телеграммасы юллады. «Сезнең сугыш кырында күрсәткән фидакарь хезмәтегез, хәрби бурычыгызга тугрылык, югары һөнәри осталыгыгыз тирән ихтирамга лаек һәм нәкъ менә бүген чын ватанпәрвәрлек, рухның какшамас көче үрнәге», – диелә республика җитәкчесенең тәбрикләвендә.
Ул Додосов һәм Габдрахмановның әти-әниләренә дә рәхмәтен җиткерде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ПЛАН БАР, КИРПЕЧ ҖИТӘРЛЕК

Быел Татарстанда 2,8 млн кв. метр торак төзеп, файдалануга тапшырырга ниятлиләр. Еллык план инде 79 процентка үтәлгән. Төзүчеләр көне алдыннан журналистлар белән очрашкан төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин планның үтәләсен әйтте.

– Моңа шик юк, – диде ул. – Безнең узган елда эшли башлаган эшләребез бар, аларын да контрольдә тотабыз. Моңа өстәп, Россиянең Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының күрсәтмәсе буенча, быелгы күрсәткечләр узган елгыдан ким булырга тиеш түгел.

Исегезгә төшерәбез: былтыр Татарстан, 3,1 млн квадрат метр торак мәйданын файдалануга тапшырып, рекорд куйган иде. Марат Айзатуллин сүзләре буенча, ипотека ставкалары күтәрелгәннән соң, Татарстанда май – июльдә фатир сатып алучылар бермә-бер кимегән, хәзер исә хәлләр җайланып килә. Бүгенгә республикада 8,5 млрд сумга 3,2 мең ташламалы ипотека бирелгән. Министр билгеләп узганча, беренче яртыеллыкта яңа төзелгән йортлар белән ипотека килешүләре саны 2018 елның гыйнвар – июнь аралыгы белән чагыштырганда 28 процентка кимегән. Ләкин соңгы 1,5 меңе ипотека ставкалары 7 процентка төшкәннән соң бирелгән.

Чагыштырып, нәтиҗә ясар өчен, узган еллардагы күрсәткечләргә игътибар итү дә җитә. Мәсәлән, 2020 һәм 2021 елларда 28 млрд һәм 25 млрд сумлык 10 мең тирәсе ипотека бирелгән булган.

– Миңа калса, без әле күрсәткечләрне тагын да арттырырбыз. Ләкин узган еллардагы саннарга ирешеп булырмы? – дип икеләнү белдерде Марат Айзатуллин.

Аның фикеренчә, ташламалы ипотека программасын тагын да озайтсалар (ә аның вакыты быел декабрьдә чыга), фатирлар төзергә һәм алырга стимул булыр иде.

– Әгәр девелопер (милек объектларын планлаштыручы һәм реконструкцияләүче. – **Авт.**) ташламалы ипотеканың тагын 2–3 елга сузыласын белсә, алга таба планнар корыр иде. Бүген ташламалы ипотека ел ахырына кадәр дәвам итә, һәм без аны 2023–2024 елларга кадәр озайтырлар, дип өметләнәбез, – диде министр.

Федераль программалар турында сөйләгәндә, Марат Айзатуллин Россия Президенты Владимир Путинның «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проектын 2030 елга кадәр озайту бурычын куйганын искәртте. Моннан тыш, Татарстан коммуналь челтәрләрне яңартуга да саллы гына акча алырга өметләнә. Әлеге программа 2023 елда эшли башлаячак. Ил күләмендә биш ел дәвамында ел саен 150 млрд сум акча бүлеп бирергә уйлыйлар. Моңа төбәкләр тагын 40 процент өстәргә тиеш була.

– Бу бик зур ярдәм – биш елга 750 млрд сум дигән сүз. Моңа кадәр төзелешкә бервакытта да мондый инвестицияләрнең булганы юк иде, – диде ул.

Дөрес, Татарстанга бу сумманың күпмесе эләгер – әлегә билгеле түгел. Акчаның 90 процентын челтәрләрне яңартуга тотачаклар. Россия буенча аларның 60 проценты тузган.

Марат Айзатуллин хәбәр итүенчә, Белем көненә Татарстанда тугыз яңа мәктәп ачылачак. Аларда 7 меңнән артык бала укыячак. Моннан тыш, мәктәпләрне яңарту буенча да республикада күп эшләр башкарыла. Мәсәлән, быел Татарстанда 140 мәктәп, ресурс үзәкләре һәм балалар бакчалары капиталь төзекләндереләчәк.

1500 балага исәпләнгән иң зур мәктәп быел Чаллыда ачылачак. Түбән Камада – ике, Әлмәттә – бер, Биектау һәм Сабада берәр белем йорты сафка басачак. Болардан кала, Казанда 18 нче гимназия һәм Кукмара районының Балыклы авылында 15 кешегә исәпләнгән мәктәп ачылачак.

Билгеле ки, журналистларны төзелештәге бәяләр һәм чит ил материалларын үзебезнекеләр белән алыштыру мәсьәләсе дә кызыксындырды. Министр сүзләре буенча, төзелеш материалларының мәгълүм вакыйгалардан соң кисәк кенә өскә сикергән бәяләре бүген нормальләшкән.

– 24 февральгә кадәр үк тимергә бәя бик нык артты. Ул хәтта 70–80 процентка кадәр күтәрелде. Бу исә барлык төзелеш материалларының бәяләре артуга китерде. Хәзерге вакытта без аларның хаклары бераз төшүен күрәбез, бәяләр тотрыкланды, – диде Марат Айзатуллин.

Аның сүзләренчә, Европадан кертелә торган төзелеш материаллары базары Белоруссия һәм Төркиягә күчте. Алай гына да түгел, төзелештә кулланыла торган күп эшләнмәләр Россия заводларында җитештерелә башлаган.

– Әгәр йорт салырга уйлыйсыз икән, анда кулланыла торган материалларның 85 проценты үз илебезнеке булачак. Шуңа күрә йорт төзүгә комачаулык итә торган проблемалар күрмибез. Авырлыклар проектны Россиядә җитештерелгән җиһазларга кабат яраклаштырып эшләгән эре объектларда гына бар, – диде Айзатуллин.

Тармакта хезмәт хаклары да арткан. Бүген бу өлкәдә хезмәт куючылар уртача 47,7 мең сум акча алып эшли. Ләкин шул ук вакытта эшчеләр саны кимегән. Бүген әлеге тармакта 81 мең кеше эшли, бу – узган ел белән чагыштырганда 92–93 процент. Министр сүзләре буенча, аларның саны чит илдән килеп эшләүчеләр азаю аркасында кимегән.

Сүз уңаеннан, матбугат очрашуы Нокса елгасы буендагы «Светлая долина» дип аталган яңа паркта узды. Министр әйтүенчә, әлеге парк быел гамәлгә кертелергә тиешле 65 җәмәгать урынының берсе. Алар өчен барлыгы 2,7 млрд сум акча бүлеп бирелгән. Бер өлеше 30 августта ачылачак.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КӨЗНЕ БҮГЕННӘН КАЙГЫРТАСЫ

Битлекне салсак та, тынычланырга иртәрәк. Белгечләр көз көне коронавирус белән авыручылар саны кабат артачак, дип фаразлый. Өстәвенә көзен елның-елында грипп та баш калкыта. Табиблар бу чирләргә бирешмәү ягын бүгеннән үк кайгырта башларга куша. Аларга каршы тору өчен иң нәтиҗәле чара дип вакцинацияне атый алар.

Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков алда әйтелгән фаразларның буш сүзләр түгеллегенә инану өчен дөньяда барган вазгыятькә күз салырга кирәк дип саный. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы китергән рәсми саннарга ышансаң, бер атна эчендә дөнья күләмендә коронавирус йоктыручылар саны 3 процентка (6,9 миллион кешегә) арткан. Июль аенда бер Төркиядә генә дә бу чирне йоктыручылар саны бермә-бер арткан. Ә ул – белгәнебезчә, Россия, шул исәптән Татарстан халкының яраткан ял урыннарының берсе. Владимир Жаворонков бу темага кагылышлы махсус туры эфир вакытында Мәскәүдә дә коронавирус белән авыручылар санының арта башлавын искәртте.

– Соңгы 2,5 ел эчендә шундый хәл күзәтелә. Мәскәүдә коронавирус белән авыручылар күбәя башласа, ике-өч атнадан безнең республикада да бу чирне йоктыручылар саны арта башлый, – ди министр урынбасары.

Жаворонков сүзләренә караганда, бүген республиканың медицина оешмаларына мөрәҗәгать итүчеләр саны арта башлаган инде. Бер тәүлек эчендә генә дә Татарстанда 82 кеше коронавирус йоктырган. Әмма бу саннары чирнең алдагы дулкыннары вакытында күзәтелгәне белән чагыштырырлык түгел. «Бүген республиканың сәламәтлек саклау тармагы бернинди тоткарлыксыз эшли. Көзгә таба авыручылар саны артачагын бик яхшы аңлыйбыз», – ди ул.

Белгеч сүзләренә караганда, бүген коронавирус, нигездә, кондиционер астында озак утырганнан соң салкын тию кебегрәк формада уза. Кеше тамак авыртудан зарлана, төкерек йоту авырлаша. Температура да күтәрелергә мөмкин.

Көзен елның-елында грипп та баш калкыта. Шуңа күрә белгечләр вирусны чирләр котырган чорга организмны бүгеннән үк әзерли башларга киңәш итә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Җәй – моның өчен иң кулай вакыт. Бакча нигъмәтләреннән организм өчен файдалы витаминнар җыеп, иммунитетны ныгытып, кояш нурлары астында җитәрлек күләмдә Д витамины алып калыр чак. Белгечләр вируслы чирләр, шул ук коронавируска, гриппка каршы иң нәтиҗәле көрәш ысулы дип вакцинацияне атый.

Владимир Жаворонков белдерүенчә, соңгы арада республика халкының коронавируска каршы вакцинациягә мөнәсәбәте яхшырган. Халык арасында уздырылган сораштыру нәтиҗәләре шуны күрсәткән. «Бүген халык вакцина ясатсаң, чирне йоктырган очракта да, аны җиңелрәк уздырасын аңлый», – ди министр урынбасары. Күп кенә чирләрне, шул ук яман шешне башлангыч стадиядә ачыкларга ярдәм итүче диспансеризация турында да истән чыгармаска киңәш итә ул. Хәзерге вакытта республикада яшәүче 60 меңләп кеше шушы тикшеренүне узган.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Язучы сүзе

Печән исе...

Туган авыл, печән өсте, киерелеп печән чабуларның матурлыгы турындагы җырлар, шигырьләр бүген дә бик күп микән? Бәлки, бераз азая да төшкәндер инде, бәлки, мин генә белеп бетермимдер. Элегрәк алар күп иде. Һәм бик ачуга тияләр, шуңа күрә колакка да эләнәләр, хәтердә дә калалар иде.

Миңа егерме бишләр тирәсе. Авыл. Печән өсте. Отпуск беткәнче гектар ярымлык посадканы чабып, җыеп, абзарга кайтарып китәргә кирәк. Бөтен гомер урманда үтә. Авылда яшәгән туганлы, дус-ишле кешегә әллә ни авыр да булмагандыр инде – кул алмаш та эшлиләр, башка җаен да табалар. Ә сиңа, кыска вакытка гына ялга кайткан кешегә, җиде кат тиреңне чыгарырга туры килә. Чабып бетереп, чүмәләгә салып куйгач та ничек алып кайтырга белми йөрисең. Техника табу җайсыз иде ул вакытларда. Колхоз техникасы колхозда эшләүчеләр өчен. Шәхси техника кыйбат, әле анысына да озын чират. Ә сиңа эшне бетереп китәргә кирәк. Аптырагач, теге техникалы абзыйга печән чабышырга, ташышырга йөрисең – шул рәвешле бераз бәясе дә төшә, чираты да кыскара. Олы бер нужа иде инде, кыскасы.

Шуңа күрә мин печән турында шигырь язган кешеләрне күралмый торган идем. Боларның барысын да бергә җыеп, авылга алып кайтып, берәр атна печән чаптырасым килә иде. Кызганычкамы, бәхеткәме, алай кыланырга насыйп булмады. Күпләре өлкән яшьтәгеләр иде. Яшьрәкләре дә бик атлыгып тормыйлар. Авылда туып-үскән кешеләр ич инде. Авылда туып, бөтен авырлыкны күреп үсеп, вакытында чыгып качкан кешеләр. Шуңа күрә авылны сагынуның бөтен рәхәтлеген татып, шәһәрдә яшәүне хуп күрәләр.

Аларны авылга алып кайтып печән чаптырырга дию «Киерелеп печән чабам...» – рәвешендәге шигырьләргә ачу килгәннән генә иде инде. Югыйсә посадкада, агач арасында, бик киерелеп чабып та булмый. Аптырау, гаҗәпләнү дә көчле иде. Ничек инде печән чапкан чакны сагынырга, шул хакта шигырь язарга мөмкин?! Мин моны берничек тә аңлый алмый идем. Монда икенең бере генә була ала: я боларга печән чабу тиешле дәрәҗәдә эләкмәгән, я аз гына кыланалар, үзләрен эшчән, булдыклы итеп күрсәтергә тырышалар.

Мин беркайчан да печән чабуны сагыначак түгел идем. Гомер буена болай печән чабып йөрү яклы да түгел идем. Мөмкинлегем булу белән сатып алу җаен каерачакмын. Хәтта чәнти бармагым да тимәгән килеш печән үзе минем абзарга килеп өелергә тиеш. Минем бөтен хыял шушы иде. «Хе, кем сатсын инде печәнне!» – дип куйды бер дустым, бу хакта ишеткәч. Ул хаклы иде. Печәнне сатучы юк. Елларның төрлесен күргән авыл халкы былтыргыдан калганын да чыгарып түгәргә ашыкмый, аерым бер җиргә өеп куя – корылык-фәлән килсә дип, запас тота. Аннан соң, көтүдәге маллар саны да бишәр-алтышар йөз белән исәпләнә. Һәр кеше өчәр-дүртәр баш сыер асрый дигән сүз. Шулай булгач, «печән сату, печән сатып алу» дигән сүз үзе үк юләрлекнең бер рәвеше булып тоела иде.

Ләкин бу хыялның чынга ашуын озак көтәргә туры килмәде. Заман да үзгәрде. Бик күп хуҗалыклар печәнне басуда үстереп халыкка сатып бирә башлады. Бәясе дә әллә ни кыйммәт түгел – бары тик ал гына. Мин дә үзгәрдем бугай. «Шундый вак нәрсә өчен үзеңне борчып тормабыз инде, күпме печән илтеп бушатыйк?» – диючеләр барлыкка килде. Ә бераздан инәй дә олыгайды, сыер асрамый башлады. Печән чабуның да, аны китертүнең дә кирәге калмады. Кайчандыр зарлана-зарлана үзем көйләгән чалгылар да келәттә ятимсерәп эленеп тордылар да кайсы кая таралышып беттеләр. Әни таратып бетергәндер инде. Үземә кирәкмәгәч, кызыксынып, төпченеп тормадым.

Тора-бара печән турындагы шигырьләр дә колакка эленми башлады. Бәлки, ул хакта язучылар да азайгандыр, бәлки, мин генә игътибар бирми башлаганмындыр. Үз ихтыяҗларың белән уртак булмаган нәрсәләрне ишетмәскә, күрмәскә гадәтләнәбез ич.

Әле бер кич подъезд алдына чыгып утырсам – тирә-яктагы үләннәрне чабып ташлаганнар. Бар дөньяда хуш исле печән исе. Печ-чән ис-се!.. Йөрәк сулкылдап куйды. Тормыштан зарлана-зарлана печән чабып йөргән чакларны хәтерләдем. Бер икеләнүсез шул чакларга кабат кайтыр идем. Чабар идем печәнен. Тик бу юлы зарланмыйча гына.

Авылдагы дус шалтыратты.

– Сездә хәзер печән өстедер инде, – дим әлеге хисләр тәэсирендә. Теге көлә:

– Заманнан артта калгансың син... Нинди печән өсте булсын инде... Хәзер печәнне сатып алабыз бит...

Марат КӘБИРОВ

КҮП АКЧА КРИЗИСЫ

Газета хәбәрчесе бүген иртән ишеткән иң беренче хәбәр: ашлык бәясе төшә. Ел саен 5–6 тонна фуражлык ашлык сатып алучы буларак, хәбәр мине сөендерә, әлбәттә. Кандагы кулланучы инстинкты тантана итә. Мин әлегә кызыксынмадым һәм бер тонна ашлыкның агымдагы бәясе күпме икәнен белмим. Бер нәрсә ачык һәм аңлаешлы: басуларда игеннәр каерылып уңды, ашлык, Аллаһ теләсә, күп булачак.

Тик күп булган әйбернең бәясе төшә. Ашлык бәясе төшүнең тагын бер сәбәбе бар: санкцияләр нәтиҗәсендә аны экспортлау мөмкинлекләре чикләнде. Базарның тараюы шулай ук бәяләрнең түбәнгә китүенә сәбәп булып тора. Югыйсә Европада рекордлы корылык, елгалар саега. Дөньяның башка почмакларыннан да шундый ук шомлы хәбәрләр ишетелә. Димәк, тышкы базарда ашлыкка бәяләр бик түбән булмас.

Кулланучы өчен бәянең түбән булуы шатлык булса да, җитештерүче өчен ул – катастрофа. Әйе, әйе, барлык башка төр товарларга бәя күтәрелгәндә, син җитештергәнгә төшсә, вазгыять синең өчен бөлдерә торганга әверелә. Бәя үзкыйммәттән дә кимесә, банкротлык яный. Азык-төлек товарлары шундый категориягә керә: аларны озак саклап булмый. Димәк, түбән бәядән булса да сатарга туры килә. Италиядә әнә фермерлар кавыннарны чүплеккә ташлый икән, чөнки эссе һава һәм язның иртә килүе бакча җимешләренең иртә һәм мул булып өлгерүенә китергән, уңыш ун тапкыр арткан. Барлык уңышны сатып бетереп тә булмый, чөнки тиз бозыла. Барысын да сатуга чыгарсаң, бәя үзкыйммәттән төшеп, бөләсең дә.

Без инфляция дип әйтәбез бит инде. Россиядә бик көчле бәяләр төшүе, ягъни дефляция кичергән товарлар бар. Әйтик, мәсәлән, алтын. 11 март көнне, россиялеләр паникага бирелеп, үз акчаларын сакларга тырышып, товар җыйганда, бер грамм алтын бәясе 7,7 мең сум иде. 5 августка 3,4 мең сумга кадәр төшкән. Акчасын алтынга тыккан халык 11 миллиард сум югалтты, диләр. Ә бит алтынны безгә иң яхшы инвестиция инструменты дип белә идек. Барлык белгечләр дә акчаны алтында сакларга киңәш иттеләр. Алтын бәясе төшүнең дә сәбәбе бик тирәндә түгел. Ул – шулай ук санкцияләр сугышы корбаны. Россия Үзәк банкының алтын резервларын сатуны тыйдылар һәм тышкы базарга чыга алмаган сары металл өчле сальто ясады – түбәнгә таба мәтәлчек атты. Безнең өчен доллар да – товар бит. Без аны да акчаны инфляциядән саклау өчен иң яхшы актив дип белә идек. Хәзер акча кирәк булса, җитмеш бишкә алганыңны илле бишкә сатарга туры килә. Доллар бөтендөнья базарында йөрүче товар иде. Товар дип язганга гаҗәпләнмәгез, нәрсәне акчага сатып аласың – шул товар инде. Хәзерге глобаль капитализмның бер гаҗәп һәм гарип ягы шунда: акчага акча сатыла. Бу үзе үк бик зур кризиска китерә. Акчаны кара көнгә саклыйм дип, доллар сатып алган россиялене күз алдына китерегез. Инвестиция инструменты буларак валюта сатып алган кешеләр белә: аны файдаланмыйсың. Бәясе күтәрелгәнен көтәсең. Ә бәя, Американың Федераль резерв системасы үзен ничек тотуга карап, бер күтәрелә, бер төшә. АКШта процент ставкасын күтәрсәләр, доллар ныгый, нефть кебек чималларның бәясе төшә, алтын да очсызлана. Хәзерге дөньяда бит нефтьне дә кирәккә дип түгел, ә акча саклау чарасы буларак сатып алалар. Әле чыгарылмаган да җир маен берничә ай алдан фьючерс дигән кәгазьләргә әйләндереп сәүдә итәләр. Кәгазьне саклау чимал саклауга караганда җиңелрәк инде, билгеле. Әмма ул котылгысыз рәвештә бәяләрнең күтәрелүенә китерә. Кайбер стандарт булмаган очракларда төшүенә дә илтә.

Шушы урында автор үз язмасының төп фикерен сөземтәсен китерә. Без базарларда күзәтә торган кризис ул – ялган акча кризисы. Рубль, доллар, евро, иена, юань, рупия... – барлык кәгазь акча да, чынлыкта, ялган акча ул. Шул сәбәпле базарда «актив» дип аталган байлык саклау инструментлары пәйда була. Бер валюта икенчесе өчен актив ролен үти, облигация, акция, фьючерс, вексель дигән алдавыч кәгазьләр барлыкка килә, фатирлар, ювелир эшләнмәләр, антиквар товарлар, картиналар (кайберсенең бер тиенлек кыйммәте дә булмый) «актив»ка әйләнә. Кеше нәрсәнедер кирәккә түгел, ә акча саклау һәм күбәйтү өчен сатып ала икән, ул «актив» дип санала. Әйтик, авторның берничә йорты һәм фатиры булуга карамастан, шәһәр читендә җир сатып алып, ике катлы алагаем зур йорт төзеп азапланган танышы бар. Моның өчен аны гаепләп булмый инде, билгеле. Бу адымга ул малын югалтмас өчен бара. Кызыгы шунда: бер кирәге булмаган фатирны яисә йортны кредитка сатып алучылар байтак. Бу торак базарындагы бәяләрнең югарылыгын, төзелеш материалларының кыйммәтлеген китереп чыгара. Быел төзелгән йорт, чынлап та, киләсе елга «актив»ка әйләнә, син аны кыйммәтрәккә сата аласың. Күпме генә төзелеш мәйданнары артмасын, фатирлар дефициты беркайчан да бетми андый вазгыятьтә. Акча чын булса, ягъни ышанычлы булса, адәм баласы байлыгын шул акчада гына саклар иде, башка инструментлар эзләмәс иде. Күз алдына китерегез: яшьләр фатирсыз интекмәс, гомере буе түләнә торган ипотека коллыгына төшмәс иде. Базарда бәяләр бик кечкенә диапазонда гына уйнар иде.

Кәгазь, ягъни ялган акча икътисады бик зур күләмдә «үле капитал» барлыкка китерә. Әйтик, матрастагы дистә миллиардлаган доллар һәм евролар икътисадка эшләмичә тик яталар. Алтын коелмалар, бәяләре күтәрелгәнне көтеп, сейфларда тик тора. Әйе, аларны банкта да саклап була. Тик ышанычлы бер генә банкны күрсәтсәгез иде сез. Малларын валюта депозитында саклаучылар бүген зар елый, чөнки валюта хисапларына тискәре процентлар кертәләр.

Бүгенге Россия бик зур күләмдә стратегик чималын һаман да компьютердагы доллар дигән саннарга сата. Сәүдә профициты 150 миллиард доллардан артып китте, дигән хәбәр укысагыз, шуның кадәр товарны чит илгә бушка озатканбыз дип аңлагыз. Хисап Россия банкында булса да, доллар дигән язуы Америка компьютерларында саклана аның. Теләсә кайсы минутта АКШның финанс хакимиятләре ул санны туңдыра да ала, сөртеп тә ташлый ала. Һәм миллиардлаган баррель нефть, тонна-тонна алтыннар, миллионлаган кубометр затлы агачлар ил икътисадына берни дә бирмичә юкка чыгалар. Кремльнең чималны сумнарда, юаньнарда, Дубай дирһәмнәрендә сатарга омтылуының сәбәбе дә шунда. Әмма ул валюталарның иясе булган илләр белән ара бозылмас һәм юаньнар бервакыт фантикка әйләнмәс дип кем гарантия бирә ала?

Социализмда (без кайчандыр яшәгән совет илендә) бәяләр тотрыклы иде. Кешеләр, шуңа алданып, Саклык банкында байтак акча җыйдылар. Әмма кәгазь акча барыбер мал саклау чарасы була алмады. Товарның дефицитын һәм сыйфатсызлыгын гына гарантияләде. Дефицит шартларында нәрсә сатсаң да алалар, шуңа күрә сыйфатны беркем дә кайгыртмады. Ахыр чиктә оекбашлар «актив»ка әйләнде, сыйфатсыз чәйне капчыклап җыйдык.

Югарыда сөйләнгәннәр хәлнең капитализмда да шуңа якын икәнен раслый. Кулында кәгазь акча булса, кеше аны отышлырак икенче нәрсәгә алыштырырга ашыга. Бик зур исраф итүгә китерә бу. Бик күп энергия чыганаклары бушка яна, кирәгеннән артык күләмдә металл һәм башка чималлар әрәм ителә. Климатның глобаль җылынуы дигән нәрсәдә кеше факторы бар дип саныйбыз икән, ул факторны ялган акча мәйданга чыгара һәм этеп йөртә. Криптовалюталар майнингы өчен бүген гаҗәп күп электр энергиясе сарыф ителә. Майнингны туктатсаң гына да хәзерге энергетик кризис юкка чыгар яисә алай ук кискен булмас иде. Ә кирәкмәгән фатирлар, автомобильләр, айфоннар һ.б. җитештерүне туктатсаң? Гаҗәп зур масштабта сугыш кораллары ясаудан баш тартсаң? Планетада һава сафланыр, кешеләр психик яктан сәламәтрәк булырлар, биржа спекуляцияләрендә теңкә корытмаслар иде.

Акчага яраклы ике генә материал бар бу дөньяда: алтын һәм көмеш. Әйләнештә алтын-көмеш тәңкәләр йөри башлау белән, без акчага акча сатып алу мәшәкатеннән котылыр идек, мал саклау өчен башка «актив»лар эзләмәс идек. Мал ишәйтүнең бер генә юлы – акчаны реаль икътисадка инвестицияләү калыр иде. Бу ике металлның сирәк очравы алардан акчаны чикләнмәгән күләмдә басу мөмкинлеген бетерә. Аңлый торгансыздыр инде: инфляция дигән куркыныч артка чигә. Бөтенләй үк бетеп җитми ул. Аны йөгәнләү өчен икътисадның башка механизмнарын да эшкә җигәргә туры килә. Шулардан файдалансаң, товарның иркеле бәясе тотрыклыга әйләнә. Бәя социализмдагыча, ә товар тәкъдим итү капитализмдагыча була. Күпләп оекбаш һәм эчке кием җыеп азапланасы булмый ягъни. Тарихта алтын-көмеш инфляциясенең берничә очрагы булган булуын. Урта гасырлар Испаниясе, Колумб Американы ачкач, бик күп таланган алтын-көмешкә тиенә. Бу испаннарның үзләрендә җитештерүне юкка чыгара, чөнки акча күп булгач, азык-төлекне дә, башкасын да чит илдән сатып алу отышлыракка әйләнә. Нәтиҗәдә ил көчсезләнә, анда инфляция чәчәк ата башлый. «Испаниядә көмештән башка бар нәрсә дә кыйммәт» дигән гыйбарә барлыкка килә. Җиңел килгән таланган байлыклар Испания империясен кабергә кумә. Шул вазыйфаны бүген дөнья күләмендә кәгазь һәм электрон акча үти.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Зөһрә
САДЫЙКОВА

ИКМӘК КАДЕРЕ

Ел да кызу урак өстендә республика басуларын йөреп кайта торган матур гадәтебез бар безнең. Сары гәрәбәдәй бөртекләрне күрү, табыннарыбызга икмәк китереп җиткерү өчен маңгай тирен түккән игенчеләр белән аралашу, тезелешеп барган кыр корабларын күзәтү – күңелгә аерым бер рәхәтлек бирә торган хисләр. Бу юлы без Аксубай районы кырларын иңләп кайттык.

Идар Мөхәммәтҗанов

«Эти эшләсә, шаккатыр иде»

Беренче тукталышыбыз Рәис Сөләйманов җитәкчелегендәге «Аксу-Агро» җәмгыяте («Агро-Инвест» идарәче компаниясе) кырлары булды. Аксубай районында аларның 30 мең гектар җирләре бар. Бу – барлык мәйданның 30 процент чамасы дигән сүз. Тагын 2600 гектар җирләре күршедәге Яңа Чишмә районында урнашкан. Без килгән көнне игенчеләр шул районның Ак бүре авылында эшлиләр иде. Шуңа күрә игенчеләрне әлеге авыл кырында куып тоттык. Бер-бер артлы тезелешкән 7 кыр корабы күзгә бодайны җыеп бетереп килә иде. Агроном Илсур Сахапов әйтүенчә, уракка игенчеләр 27 июльдә төшкән.

– Быел эшлисе килеп эшлибез. Уңыш та, уңдырышлылык та яхшы. Барысын да вакытында эшләргә тырышабыз. Бодайны тәмамлагач, арпага керәчәкбез. Шунысы куандыра: урып-җыю кампаниясендә тәҗрибәле абыйлар гына түгел, яшьләр дә катнаша, – диде ул.

Бирегә районның алдынгы игенчесе, 40 елдан артык гомерен шушы тармакка багышлаган комбайнчы Җәүдәт Сафиуллинны да очраттык. Әле ярый бераз ял итеп алган чакларына туры килдек. Алайса, кыр батырларын эшләреннән бүлдерү – журналист өчен иң уңайсызы.

– Үземне белә белгәннән бирле комбайнда инде мин. Эти дә гомере буе кырда эшләде. Мин исә 4 нче сыйныфтан бирле аңа ияреп йөри идем. Шул чакларның һәр минуты, һәр көне истә. Аннан соң шул кабинада үземнең улым үсте. 14 ел минем ярдәмчем булып эшләде ул. Быел гына башка эшкә китте. Ләкин шулай да: «Эти, елларда гына булса да эшлим әле. Күңелем ашкына», – ди. Үзем язын тракторда булсам, җәен-көзен – комбайнда. Инде үзем шушы комбайнда гына да 15 нче сезонымны эшлим. Урып-җыю чорын ашкынып көтеп алам, чөнки ул – вакытлыча гына була торган эш, – ди Җәүдәт абый. – Акча эшләп калырга да тырышабыз, әлбәттә. Бөртекле культураларны җыю аеруча ошый. Бункерны тизрәк тутырып җибәрәсе генә килеп тора. Булган уңышны исән-сау урнаштырырга язсын. Үзебез исән-сау булыйк та комбайн гына ватылмасын. Иртән 4 тулганчы торып, 5тә комбайныбыз янында инде без. Аны карап, әзерләп чыгабыз. Чөнки комбайнчы өчен иң авыры – кызу эш өстендә техника ватылу.

Уңыш яхшы булгач, игенче өчен дә куаныч. Әнә аңгәмәдәшем дә 6 мең центнер ашлык җыеп алырга өлгергән инде.

– Әле эшләрнең башы гына бит. Ел да Татарстан Президенты бүләкли торган исемлеккә эләгәм. Ә иң зур уңышны моннан ике ел элек җыеп алган идем. Ул елны 45 мең центнер ашлык суктырдым. Хәзер эшләр өчен шартлар бөтенләй башка. Чөлләдә рәхәтләнеп кондиционер астында эшлибез. Ә әтиләргә заманында хәтта кабинасыз комбайннарда эшләргә туры килде. Бу техниканы күрсә, шаккатыр иде әти, – дип елмайды алдынгы механизатор.

«Кыр эше – азарт ул»

Икенче тукталышыбыз Аксубай районының шулай ук әйдәп баручы инвесторы «Волга-Селект» җәмгыяте кырлары булды. 2017 елда эшли башлаган оешма игенчелеккә өстенлек бирә. Бөртеклеләрдән тыш, куплап көнбагыш һәм рапс үстерәләр. Быел әлеге оешма гектарыннан 32,8 центнер борчак җыеп алып, рекорд куйган. Шунысы кызыклы: инвесторда эшләүчеләрнең күпчелеге яшьләр. Без килгәндә, егетләр Шәрбән авылы янындагы кырларда көзге бодай суктыра иде.

– Механизаторларыбызның барысы да диярлек яшьләр. Һәм аларга теләсә нинди эшне ышанып тапшырырга була. Быел ике студент егет килде. Яшьләрне җәлеп итүнең иң ышанычлы юлы – яхшы хезмәт хакы түләү. Тәҗрибәле механизаторларыбыз да бар. Алар яшьләргә бар белгәнен өйрәтә, – ди идарәче Илшат Гафиятов.

Җитәкче әйтүенчә, урып-җыю – бик җаваплы чор, чөнки бу вакытта ел буе тырышлык куйган хезмәтнең нәтиҗәсен алалар.

– Эшнең нәтиҗәсе булырга тиеш. Яхшы уңыш җыеп алсак, димәк, хезмәтчәннәр дә канәгать була дигән сүз. Чыннан да, уңышыбыз мул быел. Тик аңа карап, бәясе дә булсын иде. Узган ел ашлыкны 18 сумнан кабул итсәләр, быел 12гә төшкән. Бездә уңышы булса – хакы юк, хакы булса – уңышы юк. Узган ел коры булса да, уңышны республикадагы уртача күрсәткечләрдән югарырак алдык, – диде ул.

Җитәкчеләре белән аралашкан арада комбайнчы егетләр үзләре дә килеп җитте. Эшләрен бүлдерергә кыенсынып кына, алар белән дә аралашып алдык. Чөнки егетләр чабышка әзерләнгән атлар шикелле, «вакыт әрәм» дип, баскан җирләрендә биеп кенә тордылар.

Яшь игенче Эльвир Нуретдинов тормышын авыл белән бәйләгән. Быел урып-җыюда бишенче сезонын эшли. Аңа кадәр комбайнчы ярдәмчесе булган, тракторда эшләгән.

– Авылны яратам, – дип сөйләде ул. – Яшәр өчен бөтен әйбер бар монда, исәнлек кенә булсын. Маллар да тотабыз, чөнки авылда аннан башка булмый. Акча эшлим дигән кешегә авылда рәхәтләнеп, гөрләтеп яшәргә була. Чын күңелемнән әйтәм бу сүзләрне. Эш бар, көчле инвесторлар килеп тора. Ел дәвамында, бер ай отпусктан кала, бер көн эшсез торганым юк. Ә бу чорны, гомумән, түземсезлек белән көтеп алабыз. Кыр эше – үзенә күрә бер уен, азарт ул. Беренче чиратта, әлбәттә, акча эшләп калу. Аена, премияләрдән тыш, 150 мең сум эшләргә була. Ә сезонга 400 мең сумга кадәр акча эшләү мөмкинлеге бар. Узган ел Татарстан Президенты премиясенә дә лаек булдым. Анысы да зур ярдәм бит. Менә шуңа ничек зарланып булсын?

Авылны, эшен шулкадәр яратып сөйләде Эльвир. Үзе генә түгел, балаларына да эш тәмен сеңдереп үстерә дип аңладым.

– Балалар белән табын янына утыргач, гел әйтә торган сүзем бар минем. «Балалар, белеп ашагыз. Бу икмәктә минем дә өлеш бар. Тырышып эшләсәгез, алдыгызда һәрвакыт ризык булыр», – дим. Белеп, күреп, шуны сеңдереп үссеннәр. Мин дә барысын да әтидән күреп үстем. Ул да 45 ел басуда эшләде, – ди ул. – Бер дә арттыру түгел, эшкә бәйрәмгә барган кебек барам. Иң мөһиме – комбайн гына ватылмасын. Кырга чыкканның беренче көнендә беренче бункерны машинага бушаткандагы шатлыклы хисләрне әйтеп, аңлатып бетереп булмый, – ди ул.

Ришат Гатин комбайнда дүртенче сезонын эшли. Берничә ел Чаллыда яшәгән. Тик барыбер авыл үзенә тартып кайтарган.

– Шәһәрнең «минеке түгел»леген аңладым. Анда бөтен кеше каядыр чаба, ашыга. Кырмыска оясын хәтерләтә. Ә авылда тыныч, рәхәт. Быел миңа яңа комбайн бирделәр. Яхшыга тиз ияләшәсең бит. Шуңа күңел булып, шатланып эшләп йөрибез, – ди Ришат. – Былтыргыдан соң быелгы сезонны тагын да ныграк көттек. Эшлисе генә килеп тора. Язын үзебез чәчкән ашлыкны җыеп алабыз бит инде. Эшебезнең нәтиҗәсен күргәч, рәхәт. Авыл җирендә эш бервакытта да бетми. Кулы эш белгән, теләге булган кеше югалып калмый ул.

ИҢ ЗУР УҢЫШ КАЙДА?

Район	Суктырып алынган (т)	Уртача уңыш (ц/га)
Тәтеш	91585	55
Яңа Чишмә	73991	49,5
Буа	72129	39,7
Минзәлә	62236	50,1
Нурлат	55475	38
Актаныш	54652	37,9
Аксубай	48983	37,9
Сарман	46498	43,7
Спас	46077	41,3
Алексеевск	45682	33,3

11 августка булган мәгълүматлар

Уңыш сөендерә

Аксубай игенчеләре – республикада беренчеләрдән булып уракка төшүчеләр. 11 августка булган мәгълүматлар буенча, районда барлык мәйданның 37,5 процентыннан уңыш җыеп алынган. 13 мең гектарга якын мәйданда 49 мең тонна чамасы иген амбарларга кайтарып урнаштырылган. Әлегә бер гектардан чыккан уңышның уртача күләме 37,9 центнерны тәшкил итә.

– Икмәк быел безне бик сөендерә. Кырларыбыз матур, дип шөкер итәбез, – ди район башлыгы Камил Гыйльманов. – Районда көчле инвесторлар заманча технологияләр белән эшли. Аларның яңалары да бар. Өч елда район буенча техниканың 70 проценты яңартылды. Трактор, машина һәм комбайннар – барысы да замана таләпләренә туры килә торган. Аграрийларның хезмәт хаклары да быел 134 процентка артты. Шунысы сөендерә: колхозлар беткәннән соң, кайсы кая таралышкан механизаторларыбыз арасында кабаттан җиргә әйләнеп кайтучылар бар.

Камил Гыйльманов әйтүенчә, урып-җыю кампаниясендә 90 комбайн эшли. Аларның 60ы үзләренеке булса, 30ы читтән җәлеп ителгән.

– Үзебезгә, көн саен 2,5 мең гектар мәйданда эшләргә, дигән план куйдык. Шулай итеп эшләгәндә 15 көндә көзге культураларны җыеп алырга тиешбез. Алардан кала, күп мәйданда көнбагыш (17 мең гектар), рапс (7 мең), кукуруз үсә. Аларга комбайннар чиратлап керәчәк һәм октябрьдә эшләрне төгәлләрбез дип уйлыйбыз, – ди район башлыгы.

Авыр ел булуга карамастан, барлык дәүләт ярдәмен алганнар. Ашламалар, орлыклар белән дә авырлыклар килеп чыкмаган.

– Алга таба эшләгән эшләребезнең матур нәтиҗәсен күрергә язсын иде. Шулай булганда халыкка яхшы хезмәт хаклары да, пай җирләре өчен яхшы түләү дә булачак, – ди Камил Гыйльманов.

Республика кырларыннан **1,3** миллион тонна ашлык җыеп алынган. Урып-җыю эшләре барлык мәйданның **22** процентында башкарылган. Уртача уңыш гектарыннан **39,5** центнерны тәшкил итә.

ХОЛЫКСЫЗ ҖӘЙ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Су корбаннары

Быел коену сезоны вакытында батып үлгән 39 кешенең җидесе – балалар. Узган елның шушы чорында 59 кешенең (4е – балалар) гомере суда өзелгән.

Күптән түгел Питрәч районының Шәле авылы күленнән бер-ир атның үле гәүдәсен тартып чыгарганнар. Аксубай районының Яңа Илдерәк авылы янындагы елгада да, Спас районының Ямбакты авылындагы буада да шундый күңелсез хәлләр килеп чыккан. Көн саен бер күңелсез хәбәр ишетеп торабыз.

– Фаҗиганең сәбәбе – җиһазландырылмаган урында су керү. Буа янында «Бу урында коену тыела» дигән язу эленгән. Плитәләренә дә шулай дип ике телдә язып куйган идем. Хет нәрсә дип язсаң да, күләгәдә 30 градус эссе булганда, кеше коенмыйча түзә алмый. Авыл зур бит, 1200дән артык хуҗалык бар. Буаның суы чиста. Районда, ичмаса, бер урында булса да, җиһазландырылган коену урыны юк бит, – ди Шәле авыл җирлеге башлыгы Илшат Әхмәтҗанов.

Илшат Әхмәтҗанов белдергәнчә, 49 яшьлек ир-ат авылда әнисе белән яшәгән, беркайда да эшләмәгән, еш кына эчкән. Ике тапкыр өйләнгән ир балаларына алимент түләмәгән. Мәрхүмне буага балык тотарга килүче үсмерләр тартып чыгарган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Туган нигездән берни калмады»

Яшен сугу очраклары җәй өчен яңалык түгел. Ул изге урыннарны да читләп узмый хәтта. Әнә Башкортстанның Туймазы районы Возвижение авылында яшен сугып, чиркәүдә янгын чыккан. Питрәч районының Шәле авылында берәүнең техник җиһазларына, урам баганаларындагы яктырткычларга зыян килгән. Әлмәт районының Түбән Мактама бистәсендә бер йортка яшен кереп, түбәсе һәм икенче каты янган.

Балтач районының Комзавод авылында да гает көнне күңелсез хәл килеп чыккан. 30лап йортлы авылда бер хуҗалык йорты, каралты-курасы белән көлгә әйләнгән. Әлеге хәвефне үз башларыннан кичергән Исмәгыйлевлар гаиләсе белән сөйләштек.

– Яшен иртәнге сәгать 5тә суккан. Без район үзәгендә торабыз, әмма авылга еш кайтып йөрибез. Без кайтканда янгын сүнмәгән иде әле. Урамыбызда – биш йорт. Аларда кеше яшәми. Агачлар каплап торгангамы, янгын чыкканын авылдашлар төтеннән генә күргәннәр. 1980 нче елларда күршедәге бер өйне яшен суккан иде инде, бу юлы безнекенә зыян салды, – дип сөйли Гөлназ Исмәгыйлева. – Иске һәм яңа йорт, мунча, баз, каралтылар кара күмергә әйләнде. Бер кечкенә генә кәрәк тә калмады. Шунысы гаҗәп: агачларга берни булмаган. Әни үлгәнгә – 2 ел. Күңелне иң әрнеткәне – истәлеккә бер фото да калмады, барлык документлар янып бетте. Әти белән әнине хәтерләтеп торырдай берни калмады. Шок хәлендә әле мин, ышанып та бетә алмыйм. Бу хәлне искә төшерсәләр, елый башлыйм. Ә болай уйламаска тырышам. Янгын көн саен төшкә кереп йөдәтә. Сынау дип кенә дә кабул итеп булмый. Артыграк китте.

Гөлназ – гаиләдә бердәнбер бала. Әнисе авырып торгач, Исмәгыйлевлар күп вакытларын аның янында үткәргән. Барлык көчләре шушы йортка кергән. Туган нигездә кечкенә генә булса да йорт саласы килә аның. «Безнең тормыш шунда кайный. Бәрәңгесен, җиләк-җимешен үстерәбез. Бу нигезне берничек тә ташлый алмыйм», – ди ул, күңеле тулып.

ЧАПМАСАҢ, ЧАГАЛАР

ЕЛАННАР НИК АРТА?

Авылга елан төшкән! Соңгы арада мондый сүзләр еш ишетелә башлады. Социаль челтәрләр дә шундый фотолар белән тулды. Еланнар ник арткан һәм алардан ничек котылырга? Әнә шул сорауларга җавап эзләдек.

«Бергәләп яшәргә өйрәндек»

Күптән түгел газетабызның «ВКонтакте» сәхифәсенә Балтач районының Чапшар авылында берәүнең ишегалдында тотылган елан фотосын урнаштырган идек. Укучыларыбызны битараф калдырмады әлеге хәбәр. Күпләр еланнар таралуның сәбәбен су буйлары чистартылмау, печән чабылмауга бәйләп аңлаткан. Әнә Илшат Гәрәев: «Авыл тирәләрен икешәр метр биеклектәге үлән басты, анда елан түгел, тиздән анакондалар да йөри башлар», – дип үк куркыткан. «Кешедән әшәке түгелдер әле», – дип тынычландырган бер укучыбыз. «Ахырзаман җитәр алдыннан дөньяны елан басар, ә бал кортлары әкренләп юкка чыгар, диелгән. Бүген бу күренешнең икесен дә күзәтергә була», – дип кисәткән икенчесе. Баксаң, кайберәүләрнең еланга бөтенләй исе китми икән. Гомер буе урман уртасындагы авылда яшәгән Румия Гобәйдуллина да шундыйлардан. «Авыл кечкенә булса да, буалар да күп, чабылмаган урыннар да шактый. Еланнар да, кабаннар да, поши, кәҗәләр дә аз очрамый. Еланнар хәтта өйгә, мунчага да кергәли. Йә тотып чыгарып җибәрәбез, йә үзләре чыгып китә», – дигән ул. Фальянур Арсланованың да ишегалдында керпе, кәлтә, еланның беткәне юк икән. «Сыерлар кимеде. 1990 нчы елларда бер урамда 90 сыер булса, хәзер 29–30. Халык печән чапмый», – дигән ул.

Сан

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы хәбәр иткәнчә, республикада елан чагу сәбәпле, **10** кеше хастаханәдә ятып чыккан.

Мич төбендә – елан

Әгерҗе районында бер атны елан чагып үтергәнлегеен ишеткәч, беренче булып, бу яклардагы яшәүчеләр белән элемтәгә кердек. Нindидер имеш-мимеш түгел, дөрес булып чыкты бу хәбәр. Бер фермерның аты булган ул.

– Гөмбәчеләр, себерке җыючылар күргәли икән. Мин үзем очратканым юк. Авылларда күренми алай, – ди де Тирсә авыл җирлеге башлыгы Илнар Гыйззәтуллин.

Ә менә Кырынды авылында еланнар хәтта кешеләрнең өйләренә үк керә башлаган. Ялгыз яшәүче Кәүсәрия әби иртән торса, мич төбендә, бөтерелеп, кара нәрсә ята икән. Елан икәнен белгәч, куркып калган, әлбәттә. Бер тапкыр качкан, икенче юлы тотып чыгарып җибәргәннәр. Еланга тияргә ярамый, дигән ырым буенча эш иткәннәр, кыскасы. Авылдагы буага су коенырга барган берәүнең аягын чакса. Су төбендә ятар дип кем уйлаган? Бу хакта безгә авылның абыстае Рәйсә апа Кәримуллина сөйләде.

– Авыл картая, печән чабучылар юк. Авыллар хәзер урманга әйләнеп бара бит. Урманнардан печән чабып була хәтта. Еланнар бакчада да күренә. Элек авылда елан йөрүе турында бөтенләй ишеткәнем юк иде. Урманга да җиләгенә, гөмбәсенә курыкмыйча бардык. Хәзер бакчага чыгарга да куркыта, – ди Рәйсә апа. – Өлкәннәр, гарасатлар булмасын дип, илгә тынычлык теләп, дога кыла. Яшьләр исә дөнья, акча артыннан куа. Диндә, барлык бәла-казаларга халык үзе гаепле, диелгән. Гаепне үзебездән эзләргә кирәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Корт чаккандай булды»

Зәй районының Аксар авылында яшәүче 71 яшьлек Гафият Әхмәтҗанов су буена тал сындырырга дип төшкән булган. Июль аенда елан чагып, ике атна хастаханәдә ятып чыккан ул. Баруга, реанимациягә үк салганнар. Дәваланып кайтса да, аягында шеше бетмәгән әле.

– Аякны корт чаккандай булды, шунда кара нәрсәнең үлән эченә шуышуын күрдем. Аяк куыра башлады, кыскач, кан акты. Хастаханәгә баргач, берничә укол кададылар. Рәхмәт, табиблар бик яхшы карады, – дип сөйли ул. – Быел бу бишенче очрак дип әйттеләр. Аяк астына карап йөрегез. Сак булыгыз! Хәзер теләсә кайда йөрмим, шүрләтә.

Авыл халкы, туганнары, хезмәттәшләренең барысына да рәхмәтле ул. Аларның кайгысын күтәрергә олысы да, кечесе дә булышкан. Җыештырырга бала-чагасына кадәр килгән хәтта. Кемдер акча белән, кемдер янгын кисәүләрен ташырга булышкан.

Тагын бер теләге бар әле аның. Авылдагы күперне төзекләндерсеннәр иде, ди. Янгын машиналары аның аша керә алмаган, әллә кайлардан урап узганнар. Күпер ватык булмаса, бәлкем, янгынны тизрәк сүндергән булырлар иде.

Кызуына түзәрсең...

Балтач районының Пүскән авылында быелгы җәйне онытмаячаклар. Июль аенда давыллап яуган яңгырдан соң җирләр өч көн үткәч кенә кипшергән. Кешеләр урамнарда саз ерып йөргән.

– Җәй көне шундый гарасат булыр дип көтмәгән идек. Кичкә таба булды бу хәл. Җиллэп, давыллап килде болыт. Урман, кырлардан ишелеп аккан суга беркем дә каршы тора алмады. Урамда көймә белән йөзеп була иде. Фермадагы бөтен тирес урам буйлап акты. Арткы урамда су ташкыны койма биеклегенә җитте хәтта. Ишегаллары су астында калды. Хуҗалыкларга зыян килмәде, шөкер. Су кермәгәе дип хафаланучылар булды. Яз көне бу – табигый хәл, әмма җәй өчен мондый очрак аптыратты. Бер сынаудыр инде бу. Авылыбыз тау башында урнашкан дип тынычланып утырып булмый икән. Шуңа күрә йорт яннарында канаулар казып кую кирәк. Мондый афәтләрдән Алла сакласын, – ди Рәҗәп Бәдертдинов.

Без шалтыратканда Минзәлә районының Әтрәкле авылында яңа гына давыл узган иде. Гарасат колхозның гараж, ферма түбәләрен куптарган. Тик хуҗалыкларга зыян китермәгән.

– Август аенда мондый кызу булганы юк иде. Кызу булдымы, берәр хәвеф килеп чыга инде ул. «Ык арьягы» күмәк хуҗалыгына зыян килде, тик бәясен әйтә алмыйм. Бер тапкыр җил исте дә барысын да куптарды. Кызуга түзәбез инде, бәла-казасы гына башка булмасын, – ди Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы Рөстәм Газизҗанов.

Июль аенда давыллы яңгыр Чаллы тирәсендәге бакчачылык ширкәтләренә зыян китергән иде. «Давыл бөтен алма һәм грушаларны җиргә коеп төшерде. Җил-яңгыр гына түгел, боз да яуды», – дип язган иде социаль челтәрдә «Бриз» бакчачысы. Гарасат вакытында кайбер бакчачыларның көнкүреш техникасын яшен суккан.

Белгеч фикере

Алексей ПАВЛОВ,
Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгы директоры:

– Еланнар күбәйде дигән сүз дөрес түгел. Узган ел белән чагыштырганда, уртача бер чама. Саннарын төгәл генә әйтеп булмый, кайда ничек бит. Әйтик, безнең тыюлыкта аларның саны – 9 мең тирәсе.

Бездә аларның дүрт төре билгеле. Бигрәк тә тузбаш, гади кара елан дигәннәре киң таралган. Бакыр елан да бар. Дала кара еланы дигәне бары Спас районындагы тыюлыкта гына яши. Анысы агулы санала. Кара елан кара һәм төрле төстә булырга мөмкин. Республиканың төньягында – кара, көньяк-көнчыгышта, Иделнең уң як ярында, Кама Тамагы, Югары Ослан якларында төрле төстәгеләре дә очрый.

Элек тә бар иде алар. Бер урында яшәгәч, кеше аларга игътибар да итми. Тик очратса, коткыга бирелә. Берне күрсәләр, еланнар күп кебек тоела. Быел һава эссе булды бит. Аларның күченеп йөрүе дә шул сәбәпле. Авылда чабылмаган җирләр күп. Шунда үзләренә сакланырга урын эзлиләр, иске йортларга ияләшәләр, умарталыкларда очрыйлар. Андый җирдә тычканнар күп, алар шуның белән тукланалар. Авылларда тузбашлар еш очрый. Бу төр елан тирескә йомырка сала.

Еланнардан котылу өчен, авылларда бөтен чүп-чарны җыештырырга, печәнне чабарга кирәк. Алар ачык урынны яратмый, кеше күрсәләр, үзләре качалар. Урманга барганда аягыгызга резин итек, кроссовка, өстегезгә калын кием киегез. Еланның тешләре – 3–4 миллиметр, кием аркылы үтә алмый. Гөмбәгә, җиләккә баргач, җиргә яхшылап карап утырыгыз.

Еланны үтерергә ярамый. Алар Кызыл китапка кертелгән. Моның өчен штраф түләргә туры киләчәк. Көмәнле булса, һәр эмбрион өчен өстәмә түлисе. Еланнар файда китерә, кимерүчеләрне юкка чыгара. Әйтик, еланнар булмаган җирдә тычкан бизгәге авыруы таралырга мөмкин. Елан, кимерүчеләрнең ояларына кереп, барысын да юкка чыгара. Моны берәү дә эшли алмый. Моннан тыш, кара елан агуы медицинада кулланыла. Аның бер граммы 450 доллар тора.

Сәрия МИФТАХОВА

КАДЕРСЕЗ ЛИТРЛАР

СИГЕЗ РАЙОНДА СӨТ БӘЯЛӘРЕ КИНӘТ ТӨШКӘН

Кама Тамагы районының Олы Мәрәтхуҗа авылыннан борчулы шалтырату кабул иттек. Айрат Кадыйров халыктан җыела торган сөт бәяләренең бик арзан булуын җиткерде.

– 1 июльдән районда сөт бәясе литрына 27 сумнан 22 сумга кинәт төште. Гомердә дә мондый хәлнең булганы юк иде. Районда болай да сыер асраучылар аз. Болай барса, гомумән калмаячак. Дус егет тире җыю белән шөгыльләнә. Ул да, халык терлеген күпләп эшкәртә, ди. Мондый бәяләрдән халык зар елый, әлбәттә. Авыл җирлекләре, район башлыклары ни карый? Җитәкчеләр авылны бөтенләй ташларга җыенамы әллә? Сораша башлагач, барлык районнарда да шушы хәл, дип кенә җилкә сикертәләр. Сәбәбен аңлатучы юк. Халык арасында, сөткә бәя әле тагын 18 сумга кадәр төшәчәк икән, дигән сүзләр йөри. Алай булса, эшләр бөтенләй харап, – диде Айрат Кадыйров.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Газета укучыбызның җан авазын бик яхшы аңлыйбыз. Авыл халкы терлеген рәхәтлектән асрамый. Сөт сатып, аз булса да табыш алырга өметләнә. Ләкин азыкка, электр энергиясенә бәяләр өскә сикереп, сөт бәясе менә шулай түбән тәгәрәгәндә табыш турында сөйләп була микән соң?

Белешә башлагач, мондый хәлнең тагын берничә районда булуы ачыкланды. Республиканың Идел буе зонасындагы барлык районнарында да (Апас, Буа, Чүпрәле, Кайбыч, Тәтеш, Яшел Үзән) халыктан җыела торган сөт өчен 22 сум түлиләр булып чыкты.

Чүпрәле районының Шланга авылында да халык аптыраршта. Бу якларда кешеләр терлек тотып, сөт сатып көн итә. Мәсәлән, 194 хуҗалыклы әлеге авылда гына да 352 баш сыер асрыйлар. Мөгезле эре терлекләр саны барысы бергә 900дән артып китә.

– 22 сум бик аз инде ул. Чыгымнарны бөтенләй капламый, – ди Шланга авыл җирлеге башлыгы Илдар Якупов. – 15 июльгә кадәр сөт өчен 24 сум бирделәр, шуннан соң 22 сумга төште. Безнең район халкының күпчелеге сөтне «Исток» кооперативына тапшыра. Алар инде үз чиратларында, сөтләрнең майлылыгы аз, дип аклана. Эшкәртүдән калган сөтләрен Яшел Үзәндәге заводларга җибәрәләр. Шуңа күрә чыгымнар да күп, диләр.

Сәбәпләре

Кама Тамагы районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Илфат Вәлиевкә дә чыктык.

– Бу мәсьәлә үзебезне дә бик борчый. 5 сумга кинәт төште бит, – диде җитәкче. – Менә хәзер терлекләргә ашлык сатып алырга, балаларны мәктәпкә әзерләргә кирәк. Халык өчен бик начар булды. Күрше-тирә районнарда бу хәлләр июнь ахырында башланды инде. Трейдерлар белән очрашып сөйләштем мин. Алар бу хәлнең берничә сәбәбен әйтә. Беренчесе, имеш, заводларда чимал артыгы белән күп. Җитештергән продукцияне кая куярга белмиләр. Соңгы бер елда халыкның сатып алу мөмкинлеге кимегән. Икенчедән, сөтнең сыйфаты начарлануны сәбәп итеп күрсәтәләр.

Районнарда сөт җыю бәяләре

Район	Бәя (сум)
Әгерҗе	25
Азнакай	28
Аксубай	29
Актаныш	28
Апас	22,36
Арча	30,07
Әтнә	28
Балтач	31,1
Буа	22
Югары Ослан	23
Чүпрәле	22,96
Зәй	27
Кайбыч	23
Кукмара	28,22
Мөслим	28,5
Чистай	29,68
Ютазы	27



Республика буенча – уртача 27,2 сум.
**1 август мәгълүматлары буенча*

Гадәттә, сөт бәяләре җәй башында төшә торган иде. Мондый чакта сөт җыючылар әлеге хәлне сезонга бәйләп аңлатты. Ләкин быел июньдә дә, июль башында да андый хәл күзәтелмәде. Сөт бәяләре яхшы булды. Хәер, көнбатыш районнардан кала, башкаларда бәяләр бүген дә тотрыклы. Мәсәлән, Балтач һәм Арча районнарында аны 30 һәм 31 сумнан җыялар.

Көнбатыш районнарда сөтне төрле оешмалар җыя. Тик шушы сигез районның барысында да халыктан җыелган сөт өчен 22 сум түлиләр. Аннан соң, заводлар чимал белән тулган, дигән сүзгә дә бик ук ышанасы килеп бетми. Чөнки аңа карап, халыктан сөт алу туктатылмаган бит. Кама Тамагы районында шәхси хуҗалыкларда сыерлар гомумән аз. Районда 1300 баш сыер асрыйлар. Тәүлегенә 12 тонна сөт тапшыралар. Шулай да сөйләшү ахырында Илфат Вәлиев күңелле хәбәр җиткерде. Әгәр хак булса, трейдерлар сентябрьдә сөткә элеккеге бәядән түләмәкче булалар, ди. Өметләр аклансын иде, дип телик.

Билгеле булганча, сөт җыючылар сөтнең һәр литрыннан үзенә тиешлесен чигереп, калганын халыкка тарата. Алар сүзләре буенча, республика буенча ул – уртача 1,50 тиен. Тик бөтен республикада шартлар тигез булгач, бәяләрдә аерма ни өчен зур соң? Әллә сөт заводы арзан бәядән аламы? Яки ике арада арадашчылар күпме? Әллә сөт җыючылар үзләренә тиешледән артыграк алып каламы?

Чүпрәле районында озак еллар сөт җыючы белән дә аралаштык. Ул үзенең исемен күрсәтмәү шарты белән, сөт бәяләренең менә шулай аска мәтәлчек атуын сезонга бәйләп аңлатты.

– Бездән берни дә тормый, – диде ул. – Тапшыра торган кооператив җитәкчеләреннән сорарга кирәк. Алар безгә бәяләр төшүен сезонга гына бәйләп аңлата. Аннан соң, сөтнең сыйфаты да начарланды бит. Я антибиотик чыга, я су, яки ачыган була.

Тикшерү бара

Әлеге вазгыять республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының күзәтүе астында, диде безгә министрлыкның матбугат хезмәте.

– Районына карап, сөткә бәяләр июнь ахырында 2–8 сумга кадәр кинәт төште. Сөт сатып алучылар мондый хәлнең сәбәпләрен төгәл аңлатмый һәм кире үз бәясенә кайтарудан баш тарта, – диде министрлык вәкиле.

Шулай да әлеге хәлнең чын сәбәпләрен ачыклар һәм уңай якка үзгәртер өчен министрлык Татарстан буенча антимонополия федераль хезмәте идарәсе белән берлектә тикшерү башлаган.

Зөһрә САДЫЙКОВА

15 август | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА -2» 12+
11.00 «Татар халык җырлары» 0+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «ЗАПОВЕДНИКИ» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.00 «Бердәм булыйк». Закирҗанов Тимур Рәис улы 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Каравай». Уяв-2022 12+
00.20 «Ком сәгате» 12+
01.05 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Рөстәм Мингалим турында телеочерк 6+
15.00 «Яңалыклар» 12+
15.30 «Ватандашлар» (субтитрлы) 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.00 «Яңалыклар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
19.20 «Бергә булыйк!» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Яңалыклар» 12+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05 «Башваткыч» 12+
00.00 «Яңалыклар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «МАГОМАЕВ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.40 «Большая игра» 16+
00.40 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
23.55 Сергей Маковецкий, Александр Яценко, Татьяна Лялина, Виктор Сухоруков, Артур Иванов, Мария Шумакова, Константин Крюков, Артём Ткаченко, Мария Палей, Юрий Колокольников, Игорь Миркурбанов. «ГРОЗНЫЙ» 16+
01.05 К юбилею Андрея Кончаловского. Владимир Самойлов, Виталий Соломин, Евгений Перов, Сергей Шакуров. «СИБИРИАДА» 12+
02.15 «КОРОЛЕВА БАНДИТОВ-2» 12+
04.00 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.35, 15.05, 21.30 Новости
06.05, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.40 Специальный репортаж 12+
09.30 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 15.10 «РОККИ» 16+
15.35 «ДОБРО ПОЖАЛОВАТЬ В РАЙ» 16+
17.35 «Громко». Прямой эфир
18.30 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
19.25 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Рубин» (Казань) – «Кубань» (Краснодар). Прямая трансляция
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Ювентус» – «Сассуоло». Прямая трансляция
00.30 Тотальный футбол 12+
01.00 Регби. PARI Чемпионат России. «Енисей-СТМ» (Красноярск) – «ВВА-Подмосковье» (Монино) 0+
02.55 Новости 0+
03.00 «ЦЕНА СЛАВЫ» 16+
05.15 «Громко» 12+

НТВ

04.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи» (S)
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ» (S) 16+
23.55 «ПЁС» (S) 16+
01.55 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
11.55 «Понять. Простить» 16+
12.55 «Порча». «Плесень» 16+
13.25 «Знахарка» 16+
14.00 «Верну любимого» 16+
14.35 «Преступления страсти» 16+
18.45 «Скажи, подруга» 16+
19.00 «БЛИЗКО К СЕРДЦУ» 16+
22.55 «Порча». «Тату» 16+
23.30 «Знахарка» 16+
00.05 «Верну любимого» 16+
00.35 «Понять. Простить» 16+
01.30 «Тест на отцовство» 16+
03.10 «Давай разведёмся!» 16+
04.00 «6 кадров» 16+
04.35 «Преступления страсти» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «Крещение Руси». Докудрама 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
09.55, 01.20 «ЮНОСТЬ ПЕТРА» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.00 Торжественное открытие Международного военно-технического форума «АРМИЯ-2022» и Армейских международных игр «АрМИ-2022»
13.30 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
13.50, 14.05 «Танки Второй мировой войны». Док. фильм 16+
14.00 Военные новости 16+
14.50 «ЧУЖИЕ КРЫЛЬЯ» 16+
18.50 «Битва оружейников». Док. сериал. «Вертолёты. МИ-8 против «ИРОКЕЗ». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века». Док. сериал. «Реальная история Анки-пулемётчицы» 12+
21.00 Дневник АрМИ – 2022
22.30 «Между тем» 12+
22.45 Танковый биатлон-2022. Индивидуальная гонка
23.45 «ТЫ ДОЛЖЕН ЖИТЬ» 12+
02.30 «БРАК ПО РАСЧЕТУ» 16+
04.10 «Москва фронту» 16+

16 август | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 2» 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.00 «Бердәм булыйк». Ихсанов Рәфыйк Рәшитович 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
21.00 «Ватандашлар» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Рустем Яхин. Жизнь как музыка 12+
00.40 «Каравай» 6+
01.10 «Уроки истории». Татарское просветительство 6+
02.00 «Манзара» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Рөстәм Яхин турында телеочерк 6+
15.00 «Яңалыклар» 12+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.00 «Яңалыклар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
19.20 «Бергә булыйк!» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
21.00 «Яңалыклар» 12+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
00.00 «Яңалыклар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «МАГОМАЕВ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.40 «Большая игра» 16+
00.40 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «Вечер» 12+
23.55 Сергей Маковецкий, Александр Яценко, Татьяна Лялина, Виктор Сухоруков, Артур Иванов, Мария Шумакова, Константин Крюков, Артём Ткаченко, Мария Палей, Юрий Батурин. «ГРОЗНЫЙ» 16+
01.05 К юбилею Андрея Кончаловского. Владимир Самойлов, Виталий Соломин. «СИБИРИАДА» 12+
02.15 «КОРОЛЕВА БАНДИТОВ-2» 12+
04.00 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.35, 15.05, 17.55, 20.55 Новости
06.05, 15.35, 18.00, 21.00, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.00 «ПОЗЫВНОЙ «СТАЯ» 16+
11.00 VII Армейские Международные игры «АрМИ – 2022». Танковый биатлон 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.40 Специальный репортаж 12+
13.00, 15.10 «РОККИ 2» 16+
15.55, 18.55 Всероссийская спартакиада по летним видам спорта. Волейбол. Мужчины. Прямая трансляция из Москвы
21.45 Футбол. Лига чемпионов. Раунд плей-офф. Прямая трансляция
00.55 Футбол. Лига чемпионов. Раунд плей-офф 0+
02.55 Новости 0+
03.00 «ДЖО И МАКС» 12+
05.15 «На гребне северной волны». Док. фильм 12+

НТВ

04.50 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи» (S)
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ» (S) 16+
23.55 «ПЁС» (S) 16+
01.50 Боевик «БРАТАНЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Фатальная ошибка» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «Преступления страсти» 16+
19.00 «САДОВНИЦА» 16+
23.00 «Порча». «Я вернулся» 16+
23.35 «Знахарка» 16+
00.05 «Верну любимого» 16+
00.40 «Понять. Простить» 16+
01.35 «Тест на отцовство» 16+
03.15 «Давай разведёмся!» 16+
04.05 «6 кадров» 16+
04.40 «Преступления страсти» 16+
05.30 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

04.30 «ЧУЖИЕ КРЫЛЬЯ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 18.15 «Спец. репортаж» 16+
09.55, 00.45 «ЮНОСТЬ ПЕТРА» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.15, 21.00 Дневник АрМИ – 2022
13.35 «Оружие Победы». Док. сериал. 12+
13.50, 14.05 «Танки Второй мировой войны». Док. фильм 16+
14.00 Военные новости 16+
14.50 «ЧУЖИЕ КРЫЛЬЯ» 16+
18.50 «Битва оружейников». Док. сериал. «АПЛ второго поколения. «Джордж Вашингтон» против проекта 667А «Навага» 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.30 «Между тем» 12+
22.45 Танковый биатлон-2022. Индивидуальная гонка
01.55 «ТЫ ДОЛЖЕН ЖИТЬ» 12+
03.20 «Набирая высоту. Истории про больших мечтателей». Док. фильм 16+
04.20 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 15–21 АВГУСТ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Матур йөз-кыяфәт, затлы өс-баш, акыллы сүз белән дәрәҗәле кешеләрнең игътибарын яуларсыз. Аннан инде эшләрегезнең алга китүен генә көтәсе… Атна ахырында беренче җимешләрен дә күрәчәксез!

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Гел киресен сукалаучылар белән дә мөнәсәбәтләрне бозмаска тырышыгыз. Нәкъ менә шушы араларда аларның кирәге чыгарга мөмкин. Көтмәгәндә генә бик әйбәт керем килеп керү башыгызны әйләндереп җибәрер.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Күңелгә тынычлык, рәхәтлек иңдерә торган чор. Эшләрегез гөрләп барыр, теләкләрегез үтәлер, тирәгездәгеләр сөендереп кенә торыр. Нәкъ менә хәзер тормышыгызда матур үзгәрешләргә нигез салыныр.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Эштәге шау-шу, ыгы-зыгы бераз туйдырып җибәрер. Сәбәбе – әле һаман чираттагы ялга чыгып китә алмау бугай… Ял көннәрендә телефон аша ишетелгән бер бик матур хәбәр бөтен алҗу-борчуларыгызны юкка чыгарыр.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Итагатьле булырга, шул ук вакытта үз дигәнегездә нык торырга тырышыгыз. Шулай гына адәм рәтле уңышка ирешә алачаксыз. Хезмәттәшегез, үзе дә сизмәстән бер серен ачып, сезне борчып килгән бер мәсьәләне хәл итү юлын күрсәтер.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Турысын әйткән туганына ярамаган, дисәләр дә, турыдан ярып салудан курыкмагыз. Хаклы икәнлегегез озакламый сүздә генә түгел, чынбарлыкта да күренер. Шулай итеп, тормышыгызда яңа мөмкинлекләр дә ачарсыз.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Бик күп очрашып күрешүләр, колакны торгызырдай яңалыклар, мавыктыргыч сәфәрләр чоры. Кәефегез бик нык күтәрелер, көч-куәтегез күзгә күренеп артыр, шәп кенә планнарыгыз баш калкытыр. Әле тагын яңа мөнәсәбәтләр дә бөреләнер…

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Кешеләр белән аралашудан канәгатьлек хисләре кичерерсез. Эчкерсезлек, ихласлыктан шулай бу. Бердәнберегезнең сөенечле хәбәре зур бер уртак шатлыкка әйләнер.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Атна вакыйгаларын гүя поезд тәрәзәсеннән генә күзәтеп торган кебек хис калыр. Алар тормышыгызда әллә ни чагылыш тапмыйча, күзегезгә генә чалынып китәр. Эштә беренче карашка теш үтмәслек кебек тоелган мәсьәләне хәл итәргә кемгәдер серле генә елмаеп куюгыз да җитәр.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Артык бурычларны өстегездән алып ташларга тырышыгыз әле. Инде күптәннән чираттагы ялга китәргә вакыт! Офыкта керемле урын тәкъдим итүчеләр пәйда булыр. Бермәл кызыгып та куелыр…

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Бу атна күп яхшылыклар вәгъдә итә. Әмма аларны күрә дә белергә кирәк. Эштә бик урынлы сүзләрегез күптәннән сезгә теш кайрап йөрүче кайберәүләрнең авызын йомарга мәҗбүр итәр.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Танышыгызның киңәшләрен тотып, дөрес эшлисез. Аннан инде матур планнар да кора башлаячаксыз. Ләкин ачыктан-ачык тәнкыйтьтән һәм өйдә тавыш чыгарудан гына сак булыгыз.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БУЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ГАДИ ГЕНӘ ДАВЫЛ ТҮГЕЛ

Киләсе атнада көчле магнит давыллары көтелә. Аларның беренчесе 15 августка туры килә. Икенчесе исә 17 августтан 19 августка кадәр сузылачак, дип кисәтә белгечләр. Һава торышындагы үзгәрешләргә сизгер кешеләр өчен киләсе атна бик авыр булачак, димәк. Магнит давылларына алдан әзерләнеп буламы? Бу көнне хәлне җиңеләйтү өчен нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?

Табиб-терапевт, невролог Эльвина ХАЛИТОВА шул уңайдан киңәшләрен бирде.

▶ Жир шарында яшәүчеләрнең күбесе һава торышындагы үзгәрешләргә бәйле. Бу бәйлелекнең ни дәрәҗәдә көчле булуына кешенең психологик халәте, ел фасылы, йөрәк-кан тамырлары системасы эшчәнлеге дә йогынты ясый. Магнит давыллары вакытында кеше еш кына хәлсезлек, йокысызлыктан интегә, ярсучанга әйләнә, кискен тавыш, яктылыкка сизгерлеге арта. Баш авырту, буыннар сызлау, йокымсырау кебек билгеләр дә күзәтелергә мөмкин. Күз күнә кеше магнит давылларына аеруча нык бирешә. Ник дигәндә, бу чорда организмның стрессларга каршы торучанлыгы кими.

▶ Хроник йөрәк-кан тамырлары авырулары булган, артык авырлыктан интеккән, шикәр чире диагнозы куелган кешеләр магнит бураннарына аеруча тиз һәм нык бирешә.

▶ Магнит давыллары канның куелыгына да йогынты ясый. Андый көннәрдә, гадәттә, кан куера. Бу исә – тромб килеп чыгу куркынычы да бермә-бер арта дигән сүз. Моннан тыш кан куеру нәтиҗәсендә организмда газ алмашы начарлана, күзәнәкләргә һава җитми, кан басымы күтәрелә. Шул сәбәпле, магнит давыллары котырган көннәрдә инсульт, инфаркт, гипертоник криз килеп чыгу ихтималы бермә-бер арта, баш өянәге (мигрень) диагнозлы кешеләрнең авыртулары көчәя. Шуңа күрә йөрәк-кан тамыры авыруларыннан интеккән кешеләргә магнит давыллары алдыннан профилактика ясап, кирәкле даруларны кул астында тотарга кирәк.

▶ Магнит давылларына ничек әзерләнергә? Иң элек яхшылап йокыгызны туйдырыгыз. Йокыдан кисәк торырга ярамавын да онытмагыз. Юкса баш авырта башлавын көт тә тор. Көн саен ярты сәгать булса да урамда йөреп керү өчен вакыт табыгыз. Җәяү йөрү нерв системасын ныгыта. Димәк, алда көтелгән магнит давылы көннәрен дә җиңелрәк уздыра алачаксыз. Моның өчен спиртлы эчемлекләрдән, майлы ризыктан баш тарту, чамасын белеп ашау хәерле. Мунча керергә яраткан кешеләр дә магнит давыллары күзәтелгән көннәрне җиңелрәк уздыра.

▶ Магнит давыллары вакытында майлы, тозлы, әче, ысланган ризыклардан баш тарту хәерле. Ник дигәндә, алар организмдагы суны тоткарлый. Бу көннәрдә күбрәк яшелчә, җиләк-җимеш, аерым алганда, йөзем, абрикос, мүк җиләге, караҗиләк, карлыган, лимон, банан ашарга кирәк. Алар кандагы адреналин күләмен киметә, шул рәвешле йөрәккә көч килми. Бөтнек, җиләк чәйләре, мелисса, гөлҗимеш, сары мәтрүшкәдән төнәтмәләрнең дә шифасы тими калмас. Магнит давыллары вакытында исерткеч эчемлекләр дә кулланмаска кирәк.

▶ Соңгы арада, күпфатирлы йортларда алтынчы каттан югарырак яшәгән кешеләр магнит давылларына күбрәк бирешә икән, дигән сүзләр таралды. Әмма алар дөреслеккә туры килми. Кешенең югарыда-түбәндә яшәве белән магнит давыллары арасында бернинди бәйләнеш тә юк.

Үзем сынадым

БӨТНЕКЛЕ СӨТ БУЛЫШТЫ

Мин – һава торышы үзгәрүгә бик сизгер кеше. Соңгы арада бер төнәтмәнең файдасын күрә башладым. Магнитлы давыллар көтелә, дисәләр, алдан шуны эчеп куям да бу көнне шулкадәр җиңел уздырам. Аны ясау да бик җиңел. Бер стакан кайнаган сөткә 1 чәй кашыгы кипкән бөтнек яфрагы салып болгатасың да шуны 5 минут төнәтәсең. Шуннан бөтнек яфракларын алып, төнәтмәне ярты сәгать тоткач, сөзеп эчәсең. Шифасы һичшиксез булачак.

Гөлфия ГАФИЯТУЛЛИНА.
Әтнә

Илдар Мөхәммәтҗанов

МАГНИТ ДАВЫЛЛАРЫ «КОТЫРГАН» КӨННӘРДӘ ИСТӘ ТОТАРГА КИРӘКЛЕ КИҢӘШЛӘР

✓ Физик активлыкны киметегез.
✓ Контраст душ керегез. Ул кан тамырларын тонуста тотарга ярдәм итә.
✓ Магнитлы көннәрдә тынычландыручы үлән чәйләренә дә өстенлек бирү хәерле.
✓ Көн дәвамында чиста су эчегез. Ул канны сыегайта. Димәк, магнит давыллары вакытында еш күзәтелгән тромб, инсульт, инфаркт ихтималын да киметә. Чиста су эчә алмаган кеше аны яшел чәй белән дә алмаштыра ала.
✓ Магнитлы көннәрдә самолетта очарга, метрода, җәмәгать транспортында йөрергә киңәш ителми. Беренчеләре кан басымын «уйната», җәмәгать транспортында исә һава җитмәү сәбәпле, хәлегез китәргә мөмкин.
✓ Исерткеч эчемлекләр кулланган, тәмәке тарткан кешеләр магнитлы көннәрне бермә-бер авыррак уздыра.
✓ Мондый көннәрдә кешенең игътибарлылык дәрәҗәсе 3–4 тапкыр түбәнәя. Шуңа күрә машина йөртүчеләргә аеруча сак булырга кирәк.

Файдалы

Сусауны баса

Бакчаларыбызда мул уңыш биреп утырган кыярның файдасы санап бетергесез. Ул кальций, тимер, магний, калий, фосфор, цинкка, К витаминына бай. Кыяр 96 процент судан тора. Ябыгырга теләүчеләр өчен бик файдалы.

Эссе көннәрдә, кыяр ашап, кан басымын җайга салырга була, ди табиблар. Моннан тыш, кыяр тән тиресен шомарта, апатия һәм депрессиягә каршы тору сәләтен арттыра, кан басымын һәм йөрәк ритмын нормага китерә. Әлеге яшелчәнең тагын бер яхшы ягы бар: ул хәтта бөерләрдәге вак ташлардан котылырга ярдәм итә.

Шешенүдән. 1 уртача кыярны шакмаклап турап, бер стакан суга салып, сүрән утта 5 минут кайнатырга кирәк. Әлеге төнәтмәне атна-ун көн дәвамында ашар алдыннан көненә өч тапкыр эчәсе.

Геморройдан. Яхшылап юылган кыяр өстенә тозлы су салып, суыткычка алып куегыз. Шушы суны ике атна дәвамында ашар алдыннан көненә өч тапкыр эчәргә кирәк. Бу тозлык геморрой авыруларында авыртуны баса.

Сусауны басу өчен. 5–6 кыярны блендерда ваклап, марля аша сөзегез. Тәмлерәк булсын өчен, аңа кишер согы да өсти аласыз.

Ышансаң ышан

Сагыз хәтерне яхшырта

Британия психологлары, сагыз хәтерне яхшырта, ди. Сагыз чәйнәгәндә, йөрәк мускулының кыскару эшчәнлеге арта, бу исә канга кислород килүне көчәйтә һәм кешенең хәтере яхшыра, ди алар. Табиблар әчәклегенә операция ясалган авыруларга сагыз чәйнәргә киңәш итә. Япон табиблары сагызның әчәклек эшчәнлеген җайга салырга ярдәм итүен исбатлаган. Әчәклекне дәвалау өчен сагызны көненә 3 тапкыр, ашаганнан соң 15–20 минут дәвамында чәйнәргә.

ЧИСТАРТУДА ХИКМӘТ

Соңгы 25 елда Көнбатышта тешкә бәйле чирләр 10 мәртәбә кимегән. Белгечләр моның сәбәбен андагы табибларның халыкка тешләрне ничек дөрес чистартырга, сакларга өйрәтүләре белән аңлата. Тешләрне иртәнге якта 30–40 секунд, ә йокларга ятар алдыннан 3–4 минут дәвамында чистарткан кешеләрдә кариес башлану куркынычы – 30 процентка, ә пародонтоз чире 90 процентка кими, ди белгечләр.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

ЙОМЫРКА ГЫНА, ДИМӘ

«Беренче тавык барлыкка килгәнме, әллә йомыркамы?» дигән табышмакка кешелек әллә кайчаннан бирле җавап эзли. Без әлеге сорауга җавап эзләмәдек, әлбәттә, тик Роспотребнадзор, табиб һәм диетолог мәгълүматларына нигезләнеп, йомыркага бәйле берничә сорауга ачыклык кертәбез.

Лотерея кебек

Федор Шаляпин бүләк иткән бәрхет тавыш рецептын бүген дә яратып кулланучылар бар. Сүзебез – чи йомырка турында. Аны бүген дә мускулларны үстерү, тавышны ачу өчен һәм бары файдалы дип тә кулланучылар бар. Әлбәттә, йомырканы пешергәннән соң файдалы үзлеге кимүен ящерми табиблар. Ә менә чи йомырканың сальмонеллез йоктыру куркынычы турында сөйләшкәндә, ул да лотерея билеты кебек икән: 30 мең йомырканың берсе генә аның белән зарарланган булуы бар.

Юаргамы, юмаскамы?

Роспотребнадзор йомырканы саклаган очракта юмаска киңәш итә. Чөнки юылган йомырка тизрәк бозылачак. Аның кабыгында озак саклануын тәэмин итә торган табигый саклагыч катлам бар. Җылы суда әлеге катлам бик яхшы юыла һәм шунлыктан йомырка озак саклан-маячак дигән сүз. Шуңа күрә аны озак саклыйсы булмаганда гына юыгыз, бик үк чиста булмаган йомырканы суыткычка куюдан кыенсынырга кирәкми.

Ә менә ашарга утырыр алдыннан кулны гына түгел, йомырканы да юарга кирәк. Бигрәк тә аның тышчасына тавык каурыйлары, пычрак ябышкан булса, сабынлы җылы суда юып алырга киңәш ителә. Чатнаган йомырканы чиле-пешле итеп пешермичә, каты итеп пешерүең хәерле. Чөнки ни дисәң дә, сальмонеллез куркынычы турында онытып җибәрергә ярамый.

Ишектә сакларга ярыймы?

Роспотребнадзор, суыткычның ишегендә йомырка куяр өчен урын булса да, анда куймаска киңәш итә. Шулай ук сөт ризыкларын да ишеккә куймавың хәерле дип кисәтәләр. Чөнки йомырка белән сөт ризыкларын бертөрле температурада саклау яхшырак. Ә менә ишекне бер ачып, бер ябып торганлыктан, андагы температура гел үзгәреп тора.

Суыткычта саклау мәҗбүриме?

Роспотребнадзор мәгълүматларына караганда, суыткычта йомырка өч айга кадәр үзлеген югалтмый бик яхшы торачак. Ә бүлмә температурасында йомырканың «гомере кыскара», 25 көнгә генә кала. Шулай ук йомырка сатып алганда аны савытларга тутыру вакытын да карарга онытмагыз. Ташлама дип, яраклылык вакыты чыккан йомырка ала күрмәгез.

Ак йомырка начармы?

Халыкта ни өчендер йомырканың ак кабыклысыннан кала төрле төстәгесе файдалырак дигән уйдырма яши. Ак йомырканы тәрбия җитмәгән мескен тавыкныкы шикелле кабул итүчеләр дә бар. Чынлыкта йомырка кабыгы төсенең бернинди дә әһәмияте юк. Шулай да ак кабык бераз нечкәрәк булганлыктан, тизрәк яньчелә. Әмма моның бер зыяны да юк, аның эче шул ук бит.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сарысы җетерәкме?

Күпләр йомырканың сарысы җете булганны ярата. Авылның сары эчле йомыркасыннан токмач бөтенләй икенче инде, диючеләр дә бар. Йомырка сарысының җетелеге тавыкның ашавына бәйле. Аның рационы байрак булган саен, сарысы җетерәк була.

Тазартамы?

Җәй көне йомырка бигрәк тә күп ашала. Ябыгырга теләүчеләр арасында, йомырка сарысы тазарта дип, күбрәк агына өстенлек бирүчеләр дә очрый. Чынлыкта йомырка агы тиз һәм җиңел, ә сарысы озак һәм авыррак үзләштерелә. Әлбәттә, билегез нечкәрәк булсын дисәгез, агын гына ашарга да мөмкин. Әмма сарысында протеин, Д витамины, антиоксидант һәм бавыр эшчәнлеген яхшырта торган холин барлыгы турында да онытмагыз. Шуңа күрә йомырка сарысын ташлаганчы башта уйлагыз.

Ә күләменә килгәндә, сәламәтлек буенча чикләүләр булмаганда, көненә 1–2 йомырка ашауның бер зыяны да юк.

Киңәш-табыш

ТАПНЫ МАЙ БЕТЕРӘ

Күптәнге, бетереп булмый торган таплардан котылуның бер ысулы бар. 5 л суга 1 аш кашыгы персоль (җиләк-җимеш, кофе, чәй тапларын бетерә торганы), 1 аш кашыгы үсемлек мае, ярты стакан кер порошогы кирәк була.

Барысын да суда эретергә. Юылган таплы киемнәрне шул суга салырга. Болгатырга һәм су кайнап чыкканчы утта тотарга. Аннары сүндереп, капкач капларга. Ак керләрне – аерым, төслеләрне аерым кайнатырга. Иске тапның эзе дә калмаячак.

Үзем сынадым

Суган, сарымсак алганнан соң түтәлләр бушап калды. Мин әлеге түтәлләрнең бер өлешен тик тотмыйм, ел саен укроп белән кыяк өчен суган чәчәм. Аларны көзен куллану өчен генә түгел, ә махсус катыру өчен дип утыртам. Чөнки көзен чәчкән укроп белән суган кыягы язгысы кебек үк сусыл булмый, шунлыктан кышка катыру өчен яхшы. Көзге тәмләткечләр укмашмый, киләсе җәйгә кадәр менә дигән булып саклана.

Зөлфия ДӘҮЛИЕВА.
Мамадыш

Тәмле булсын!

Витаминлы бомба

Роза НУРГАЛИЕВА рецепты

Ике кг кара карлыган, берәр кг әфлисун белән лимонны иттарткычтан чыгарырга. Шуңа 5 кг шикәр комы өстәп, шикәре эреп беткәнче болгатырга. Витаминлы тәмлүшкә әзер дә. Аны савытларга салып, туңдыргычта сакларга.

Карбызлы салат

Әдилә САФИНА рецепты

Кирәк: *төше алынган карбыз – 300 г, брынза – 100 г, ярты баш кызыл суган, 7–8 данә зәйтүн, 1 чәй кашыгы сыек бал, 1 аш кашыгы бәлзәм серкәсе, бераз гына кипкән бөтнек һәм зәйтүн мае.*

Шакмаклап туралган карбыз белән брынзаны, ярымбоҗралап туралган суганны һәм зәйтүнне тәлинкәгә салырга. Зәйтүн мае, бәлзәм серкәсе һәм балны болгатып соус ясарга һәм аны тәлинкәдәге салат өстенә сибәргә кирәк. Бик тәмле, файдалы һәм җиңел салат әзер!

КИШЕР ЯФРАГЫ БЕЛӘН ПОМИДОР МАРИНАДЛАУ

Резеда ӘХМӘДУЛЛИНА рецепты

«Әлеге рецепт буенча күпме ясасам да, Яңа елга кадәр бетә.

Стерильләштерелгән банкаларның төбенә мулрак итеп яхшылап юылган кишер яфрагы, 1 л банкага 1 тырнак исәбеннән сарымсак салабыз. Помидорларны тутырабыз да, кайнар су коеп, 15 минут тотабыз. Шул арада тозлык әзерлибез.

1 л суга 1 аш ашыгы тоз, 5 аш кашыгы шикәр комы, 70 г 9 процентлы серкә салабыз.

Банкалардагы суны түгеп, кайнап чыккан тозлыкны помидорлар өстенә салып, тимер капкач белән каплыйбыз. Җылы әйбер белән төреп куябыз. Эше дә ансат, бик тәмле дә!»

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЯЛНЫҢ ДА ЧАМАСЫ БУЛА

Көтеп алган җәйнең соңгы аен ваклыйбыз. Җәйге ял сезоны тәмамланырга да күп калмый. Быел ул тынгысыз, хәвефләрәк булды. Суга бату очраклары, чит илдә ял иткәндә, машина белән сәяхәткә чыкканда, казага тару турында хәбәрләр әледән-әле ишетелеп торды. Оренбургтан тауларга ял итәргә киткән тулы бер гаиләнең өйләренә мәетләре генә әйләнеп кайтты. Сәфәр – Аллаһы Тәгаләнең сынавы, диюләре хакмы? Мөселман кеше ничек ял итәргә тиеш?

«Казан нуры» мәчете имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт МӨХЛИСОВ белән шул сорауларга җавап эзләдек.

:: Быел ял итәргә киткән җирдән хәвефхәтәргә тару, үлем-китем очраклары бик нык артты. Кешеләр тормышларын, белә торып, куркыныч астына куялар. Мондый ялга ислам дине нинди мөнәсәбәттә?

– Исламда ял итү, ялга бару, сәфәр кылу тыелмаган. Киресенчә, сәфәр кылсак, төрле җирләрдә булсак, ул тормышка карашыбызны үзгәртә, яңа кешеләр белән танышабыз, яңа төр ризыклар татыйбыз, кемнәрнеңдер тормышына карап гыйбрәт алабыз, шаккатабыз, кызыгабыз, йә булмаса: «Аллаһка шөкер, үзебезнең тормыш яхшырак, матуррак икән», – дип шөкер итәбез. Шул яктан караганда, сәфәр кылу динебездә тыелмаган. Киресенчә, куркәм санала. Әмма ял иткәндә чама, саклык хисен дә югалтырга ярамый. Бигрәк тә, адреналин артыннан куып, тормышыбызны куркыныч астына куюдан да сакланырга кирәк. Ялда чакта кеше еш кына үз-үзен саклау кагыйдәләрен онытып җибәрә. Әмма бу очракта тормышыбыз, сәламәтлегебезне саклауның безнең өчен Аллаһы Тәгаләдән бирелгән әманәт икәнен онытмаска кирәк. Без аларны куркыныч астына куярга тиеш түгел.

:: Мөселман кеше ничек ял итәргә тиеш? Дин күзлегеннән караганда, дөрес ял нинди була?

– Мөселман кеше кая гына барса да, нинди генә матур җирләр күрсә дә, Аллаһы Тәгаләнең күргәнлеген, аның каршында җавап бирәсе бар икәнен онытмаска тиеш. Динебез ял итүгә билгеле бер шарт, таләпләр куя. Ял итәргә барган урыннарда хәрәм ризык, хәрәм эчемлекләрдән сакланырга кирәк. Гыйбадәт-намазларыбызны да калдырмау шарт. Ял иткәндә зинадан, бозык сүз, бозык гамәлләрдән дә саклану мөһим. Кайда гына булса да, мөселман хатыны ялыктан йөрергә, гаурәт җирләрен томаларга тиеш. Ир-атлардан да, гаурәт урыннарын каплап, башка гаурәтләргә карамау сорала. Бүген ир-атлар өчен дә, хатын-кызлар өчен дә шундый махсус коену киемнәре бар.

:: Бурычка, кредитка ял итәргә бару дөресме?

– Бурыч алып ял итәргә барырга була. Әмма бу гамәл бик килешеп бетми. Ял итү – мохтаҗлык, ниндидер кичектереп булмаслык зарурият түгел. Шуңа күрә мөмкинлегебез юк икән, ялны чит илгә бармыйча, артык акча чыгармый торган башка ысуллар ярдәмендә үткәрергә кирәк. Әмма ял өчен кредит алу тыелган. Мөселман кеше бурычка 100 сум алса, 100 сум кайтарып бирергә тиеш.

:: Исламда ял фәлән көннән артмаска тиеш дигән чикләү бармы? Озын ялларвакытны исраф итү дип саналмыймы?

– Андый таләп юк. Әмма кирәгеннән артык ял итеп, вакытны да, малны да исраф итүдән сакланырга кирәк. Юкса ялкаулыкка, төшенкелеккә бирелүебез бар.

:: Җәен күпләр үз транспортында юлга, сәяхәткә кузгала. Машинада утырып барганда, ничек намаз укырга?

– Сәфәргә гаиләбез белән чыгып китсәк, нинди юллардан барачагыбызны алдан карап куярга кирәк. Әгәр мөселманнар яшәгән җирләр, мәчетле урыннар аша барсак, намазны шунда кереп укысак – иң күркәме шул. Мондый мөмкинлек булмаса, туктап, намазлыгыбызны җәеп, кыйбланы чамалап, намаз укыйбыз. Автобус белән сәфәр кылабыз икән, намазны утырган килеш кенә укыйбыз. Үзенең яши торган җиреннән 85 км ераклыкка киткән кеше юлчы санала. Аңа намазны кыскартып уку рөхсәт ителә. Килгән җирендә 15 көннән озакка калса, ул юлчы булып саналмый һәм барлык намазларны да кыскартмыйча укырга тиеш була.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Исламда сәфәр сынау санала. Сәфәрдә, сәяхәттә кеше ни рәвешле сынала? Бу сынауны узуның билгеле бер шартлары бармы?

– Сәфәр – дөрестән дә, сынау. Элегрәк кешеләр атлар, дөяләр белән, җәяү сәфәр кылып азапланса, хәзер инде, Аллаһка шөкер, яхшы машина, поезд, очкычларда ерак араларны тиз арада үтәбез. Әмма шуңа да карамастан, сәфәр кылуның хәзер дә үз кыенлыклары бар. Әйтик, аэропортка барабыз икән, рейсның билгеле бер вакыты бар – өлгерергә кирәк. Шуңа өстәп әле берничә кат тикшерү дә узарга кирәк. Чит җирләрдә йөргәндә кеше тел белмәскә мөмкин. Шул рәвешле кеше сәфәрдә рухи яктан бик нык сынала. Мөселман кешенең төп бурычы – аларны лаеклы рәвештә үтеп, Аллаһының рәхмәтенә ирешү.

Белеп тор!

✓ Аллаһы Тәгалә Коръәндә «Ганкабут» сүрәсенең 20 нче аятендә: «Әйт, ий Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.): «Җир өстендә йөрегез һәм гыйбрәт илә карагыз – Аллах кешеләрне ничек төрле итеп халык кылган, соңра хөкем итәр өчен үлгән кешеләрне барын да тергезер, Аллаһның һәр нәрсәгә көче җитәдер», – ди.

✓ Мөхәммәд (с.г.в): «Сәфәр кылыгыз һәм сәламәт булырсыз», – дигән. Әбү Хурайра җиткергән хәдис (Әхмәд җыентыгы).

✓ Гали әбү Талиб (р.г.): «Сәфәр кылыгыз, сәфәрдә 5 файдалы әйбергә өйрәнеп була, – дигән. – Беренчедән, ул күңелсезлекне бетерә. Икенчедән – малны, өченчедән гыйлемне арттыра. Дүртенчедән, әхлакка өйрәтә. Бишенчедән, яхшы кешеләр белән дуслаштыра».

✓ Өч төрле сәфәр бар: беренчесе – гыйлем алу өчен, икенчесе – кәсеп кылу өчен, өченчесе – күңел ачу өчен. Бу сәфәрләр Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алу өчен булырга тиеш.

✓ Расүлуллаһ (с.г.в.) әйткән: «Кем гыйлем алу өчен сәфәр чыкса, фәрештәләр шул кешенең аяк асларына канатларын җәярләр. Күктәге һәм җирдәге мәхлукатлар, хәтта диңгездә булган кит балыгы да сәфәр чыккан кеше өчен Аллаһы Тәгаләдән гафу кылуын сорарлар. Ул кешегә җәннәткә юл җиңеләяр икән».

Ни кылсаң да, үзеңә

(ГЫЙБРӘТЛЕ КЫЙССА)

Бер фәкыйрь байның ишегенә теләнеп килә. Бай исә аны таш атып куалап җибәрә. Шунда фәкыйрь, бай аткан ташны куенына салып, ант итә: «Әй, баеган, муллыкта яшәүче кеше, бу ташны үзеңә кайтарып атканчы аны кулымнан ташламам!»

Шуннан соң күп вакытлар үтә. Тормыш тәгәрмәче сыман әйләнә. Шул байның да гаепләре табыла. Ул мәхкәмәдә оттыра. Аның бөтен мөлкәтен тартып алалар, үзен таш атып үтерүгә хөкем итәләр. Таш ату вакытында шушы фәкыйрь дә килеп җитә. Ул да атмакчы булып, күптән куенында саклаган ташны чыгара. Шунда уйланып калып, болай ди:

– Хәтерлисеңме, син мине, фәкыйрьне, таш атып куалаган идең. Бу көндә исә таш ату нәүбәте миңа җитте. Әмма синең кебек һичнәрсәсе булмаган адәмгә таш атып рәнҗетмәм.

Шушы кыйссадан нәтиҗә шулдыр: фәкыйрь гәрчә начарлык күргән булса да, начарлык белән кайтармый. Бай исә үзе кылганыннан үкенүгә кала. Менә ни өчен борынгылар: «Нәрсә генә кылсаң да, үзеңә кыласың», – дигән.

Йөгез, бер дога!

МУНЧАДАН ЧЫККАНДА УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

«Әл-хәмду лилләәһилләзии әзһәбә ганнил-әәзәә вә гаафәәнии».

Мәгънәсе: «Миннән борчуны алып, саулык һәм сәламәтлек биргән Аллаһыга мактау булсын».

ЭШ БАШЛАГАНДА ЯИСӘ ЭШ ВАКЫТЫНДА УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

«Әллааһүммә иннии әс-әлүкә сыйххәтән вә гаафийәтән вә гыйльмән нәәфиган вә ризкан хәләәлән таййибән вә гамәлән мәкъбүүлән».

Мәгънәсе: «Аллаһым! Синнән исәнлек-саулык, файдалы гыйлем, гүзәл һәм хәләл ризык, кабул булачак гамәл һәм эш телимен».

* * *

Әгәр дә Аллаһтан җәннәт сорасагыз, Фирдәвес җәннәтен сорагыз, чөнки ул җәннәтнең уртасы һәм иң бөеге...

Лилия ГЫЙМАЗОВА

РӘЗӘЛ ЗЫЯТДИНОВ: «ЯШЬЛӘР ГАРМУНГА БИТАРАФ ТҮГЕЛ»

«Ни хәл?» сәхифәсенә кунакка яшь баянчы Рүзәл ЗЫЯТДИНОВны чакырдык. Гармунны өч яшендә үк үз иткән егет белән иҗат, һөнәренең үзенчәлекләре, гаилә һәм... кызлар турында сөйләштек.

Үзе турында

:: Ни хәл?
– Бар да яхшы, Аллага шөкер! Җәй бик кызу уза. Тик торган юк, эшлибез дә, ял да итәбез.

:: Рүзәл, тәүге тапкыр кулыңа баян алган көнең исеңдәме?
– Ул вакытта миңа нибары өч яшь булган. Дөрес, баян түгел, башта гармун тотып караганмын. Балалар бакчасында кулыма гармун тотып, «Әссәләмәгаләйкум» җырын башкарганмын. Ә баян белән чын-чынлап Балтач музыка мәктәбендә «очраштык» без. Аннан шул мәктәптә җиде ел укыдым.

:: Якыннарың иҗади һөнәр сайлавыңны хупладымы?
– Әлбәттә! Әнием мине баян классына бик теләп укырга бирде, ә әтием баян бүләк итте. Иҗат юлын сайлавыма каршы килмәделәр. Мин кечкенәдән, бер бәйрәмне дә калдырмый җырлый идем. Тик менә баянчы булып киттем.

:: Гаиләңдә иҗатка гашыйк кешеләр тагын бармы?
– Әтием дә, әнием дә, абыем да бик матур җырлыйлар. Әни әле шигырьләр дә язарга ярата.

Һөнәр турында

:: Соңгы арада сәхнәдә яшь баянчылар артып китте. Нәрсә җәлеп итә сезне?
– Элек-электән баян, гармун моңы халкыбызның күңелен җилкендергән, юаткан, сагышландырган. Замана үзгәрә, дибез. Нинди генә үзгәрешләр булса да, «моң» төшенчәсе шул ук халәттә яши бирә. Сәхнәдә яшь баянчылар күп икән, без моңа сөенергә генә тиеш. Миңа калса, моңны тоеп, аны күңелең аша үткәргәндә генә үзеңне тулысынча бәхетле хис итәсең. Менә шул кабатланмас моң җәлеп итә дә инде безне.

:: Сәхнәнең үз кагыйдәләре бар, ә баян – һәрдаим шөгыльләнүне таләп итә торган уен коралы. Моңа вакытың каламы?
– Теләге булган кеше вакытын таба ул.

:: Гармун, баян уйнау – бер хәл, әле бит аларны хәстәрләп торырга да кирәк. Кыйммәткә төшәме ул?
– Баян, тальян, гармун – барысы да күз карасы кебек саклауны таләп итә торган уен кораллары. Шөкер, ватыла калсалар, төзәтеп бирә ала торган осталарыбыз бар. Бәяләре бик «тешле» торган димәс идем.

:: Баянчы булып кына тамак туйдыру мөмкинме?
– Баянчы булып кына, дию дөрес булырмы икән? Баянчы булу нәрсә инде ул, бик җиңел бит, дип уйлаучылар бар. Ләкин ул да – һөнәр бит. Һәр һөнәрнеке кебек аның да үз авырлыгы, уңай һәм тискәре яклары бар. Ә тамак туйдыруга килгәндә, шөкер, бүген безгә, яшьләргә, моның өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар.

:: Рүзәл, ничек уйлыйсың, баянчылар да концертлар куя башлармы икән берзаман? Син куяр идеңме?
▶ Интернет аша нидер сатып алганда, ниндидер хезмәт өчен акча күчергәндә, бу сайтны яхшылап өйрәнү мөһим. Шулай ук башка кулланучыларның кайтавазларын өйрәнү дә зыян итмәс. «Предоплата», өстәмә түләү соралган очракта да, җиде кат уйларга киңәш ителә.

Россиянең Цифрлы үсеш министрлыгы, IT-тармак вәкилләре белән берлектә, шәхси мәгълүматны ачык әйләнешкә керткән өчен штраф куллану турында закон проектын август аенда камилләштереп бетерергә исәпли. Элегрәк билгеле булганча, юридик затларга штраф күләме – 60–100 мең, кабат хокук бозган очракта 500 мең сумны тәшкил итә.

Инициатива авторлары штрафларны ике этапта кулланырга тәкъдим итәләр. Беренче очракта штраф күләме билгеләнгән булса, икенче этапта инде компаниянең керем күләменә бәйле рәвештә (оборотный штраф. – **Авт.**) салырга уйлыйлар. Моннан тыш, әгәр шәхси мәгълүматны саклау буенча компания азмы-күпме тырышканлыгы ачыкланса, моны штраф салганда карарны «йомшарту» сәбәбе итәргә дә мөмкиннәр. Кире очракта җәза да катгыйрак булачак.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КЕШЕ БӘХЕТЕ ӨЧЕН ТУГАН БАЛА

Җаннарны тетрәндергән канкойгыч сугышларда батырлыклар күрсәткән гүзәл затларыбызның гамәлләре гаҗәпләндерә дә, сокландыра да. Илебез азатлыгы өчен көрәш. Сүз дә юк, нәкъ менә шушы идеология аларны ут эчендә кайнарга өндәгән. Шундый кызларыбызның берсе – Гражданнар сугышында катнашкан Зөһрә Алтынбаева.

Гадәт буенча, нинди булса да мәгълүмат алырга теләп, беренче чиратта аның туган җире – Нурлат районындагы Ерыклы авылына шалтыраттым. Бу авылны үз эченә алган Биляр-Озеро җирле үзидарәсендә аның турында ишеткән кеше табылмады. Димәк, архив тузанында яткан документларны дөньяга чыгаручылар булса гына, Зөһрә Алтынбаеваның исемен киләчәк буын искә алыр дип өметләнергә була.

«Казанга кайтасым килде»

– Архив материалларында әти-әнисе хакында мәгълүмат сакланып калмаган, – ди бу җәһәттән галимә Тәэминә Биктимирова. – Ә менә бертуган абыйлары Миңнәхмәт, Хөснулла, Сөләйман, Ибраһим, Әхмәткәримнең сеңелләренә ярдәм итүләре турында әйтелә. Алар Зөһрәгә Уфа шәһәрендәге рус-татар мәктәбендә белем алырга да булышкан. Гаиләдә матур тәрбия алып үскәннәрдер дип уйлыйк егетләрне, шулай булмаса, туганлык мөнәсәбәтләре мондый җылы һәм җаваплы булмас иде.

«1916 елда Уфада укуны тәмамлагач, мин Красноводск тирәсендәге төрекмән авылында мөгаллимә булып урнаштым. Әллә бөтенләй ят җир булганга микән, Казанга кайтасым бик килде», – дип яза Зөһрә апа.

1917 елда ул Казанда яши башлый. Мәгълүм булганча, Февраль революциясеннән соң Казан гөрли. Һәртөрле партияләр үзләренең эшчәнлеген җанландыра. 1917 елның апрелендә «Яңа клуб» бинасында – татар хатын-кызларының, «Мөхәммәдия» мәчетендә татар мөгаллимнәренең корылтайлары үткәрелә. Мулланур Вахитов җитәкчелегендә Мөселман социалистлар комитеты оештырыла. Ул хакимиятне ярлы халык Советларына бирү, барлык җирләрне җир комитетларына тапшыру, завод-фабрикаларны, табыш бирә торган йортларны дәүләт милкенә әйләндерү кебек эшләр белән шөгыльләнә. Бу оешманың органы буларак, «Кызыл Байрак» газетасы нәшер ителә башлый. Комитет төрле оешмалар, сәнәгать предприятиеләре белән элемтә урнаштыра. Эшчеләр арасында агитация-масса эшләрен җәелдереп җибәрә. Һәр эшкә җаваплы кешеләр билгеләнә. Эшче хатын-кызлар арасында аңлату эшләрен комитет Әминә Мөхетдинова белән Зөһрә Алтынбаевага йөкли. «Мин «Кызыл Байрак» гәзитен әзерләп почтага салу һәм халык арасында тарату эшләрен дә үз кулыма алдым. Мулланур иптәш Вахитов минем эшемне югары бәяләде», – дип яза Зөһрә Алтынбаева истәлекләрендә.

Боларга өстәп, ул комитетның Елга аръягында урнашкан Алафузов фабрикасы эшчеләрен укытуны да үз өстенә ала. Фабрика театрының беренче катында урнашкан бүлмәгә яше һәм карты, укый белгәне һәм хәреф танымаганы, татары һәм чуашы, алар сөйләгәнне аңлаучы руслар җыела. Барысының да күңеленә ачкыч таба ала Зөһрә. Эшчеләрнең матбугат белән кызыксынулары да арта бара. Шуларны искә алып, комитет Ленинның популяр әсәрләрен тиз арада тәрҗемә итеп чыгарырга карар бирә. Бу хәл Зөһрәгә дә, аның кебек башка пропагандистларга да эшлекле ярдәм була. Октябрь ае вакыйгаларын алар зур әзерлек белән каршы ала.

Тарихтан укып белгәнебезчә, 1918 елның апрелендә Мәскәүдә татар-башкорт батальоны оеша. Мулланур Вахитов аның комиссары итеп билгеләнә. Батальон сугышчыларын Көнчыгышка җибәрергә карар кылалар. Аларны тантаналы төстә Кызыл Мәйданга чыгарып тезәләр. Мулланур Вахитов, чыгыш ясаганнан соң, батальонга сугышчан Кызыл Байрак тапшыра. Аңа «Революция дошманнарына – үлем!» дип язылган була. Аларны тынлы оркестр белән Казан вокзалына озаталар. Милли составы шактый чуар булган бу батальон акгвардиячеләргә каршы көрәштә зур батырлык күрсәтә. Сугышчылар арасында Мәскәүдәге туганнары белән көрешергә дип килгән Зөһрә Алтынбаева да була.

realnoevremya.ru

Очраклы хәл түгел бу

Зөһрәнең батальон сугышчылары сафына басуын очраклы хәл дип булмый, әлбәттә. Ул бу хакта бик озак уйлангандыр. Үзе дә истәлекләрендә турыдан-туры әйтмәсә дә, шундыйрак фикер калдыра.

Батальон төялгән поезд Түбән Новгород шәһәренә җиткәндә, акгвардиячеләрнең Самараны алулары билгеле була. Димәк, яңа оешкан кызылгвардиячеләр турыдан-туры ут эченә барып керә диган сүз була бу. Батальон Көнчыгыш фронтның Сызрань участогына җибәрелә. Шәһәргә килеп җитәргә егерме чакрымнар кала, Троицк авылы янында батальон акгвардиячеләр белән беренче тапкыр йөзгә-йөз очраша. «Татар-башкорт батальоны сугышчылары арысланнар кебек сугыштылар», – дип языла «Кызыл Байрак» газетасының 1918 елгы 19 июль санында. Каты бәрелештән соң 250 сугышчыдан нибары 47се генә исән кала.

Зөһрәгә төрле сугышларда катнашырга туры килә. «Минем көчем күп керде, – ди ул. – Норлат янында Кызыл Армия зур һөҗүмгә күчте. Ә мин станциядә җиләк-җимеш, папирос саткан булып, бөтен хәлне аңлатып, фронтка язып тордым. Кызыллар килгәч, кулга төшкән хәзинәләрне алып барып тапшырдым».

Разведчик

Бөгелмә шәһәрен азат иткәндә ул бөтенләй разведкага күчә. Дәүләкән станциясендә задание үтәгәндә, аклар кулына әсирлеккә төшә. Аны элек Казанда күреп белгән бер колчакчы танып ала да тиешле җиргә хәбәр итә. Кыз баланы җәзалыйлар, атарга хөкем итәләр.

> Әмма ул исән кала. Җәек елгасын үткәндә вагон тамбурыннан сикереп төшә дә, мең бәла белән Курган шәһәренә килеп җитеп, большевикларга кушыла. Сәламәтлеге нык какшый. Омск шәһәрендә кемнәрнеңдер ярдәме белән хастаханәгә кереп дәвалана.

Тик Себер якларында да хәлләр гел үзгәреп торган. Әле бу вакытта кызыллар, сугыша-сугыша, Петропавловскига гына якынлашып килгән булалар. Зөһрә Семипалатинскида яшәгән туганы Гарифулла янына сыенырга мәҗбүр була. Әмма үзен кызыл сугышчы дип санаган Зөһрә биредә дә тыныч яши алмый. «Мин Күкпикти (Семипалатинскидан ерак түгел Кокпекты шәһәре хакында сүз бара. – **Авт.**) шәһәрендә Колчак армиясеннән качкан егетләрне кулга ала башлауларын ишеттем. Аларның исем-фамилияләрен язып, мәгълүмат җыя башладым. Акларның көне беткәнен сизә идем. Чөнки Омскидагы байларның да шәһәрдән кача башлаулары хакында хәбәрләр тулы иде», – дип яза ул.

Комиссар

Семипалатинск ягындагы таулар арасында партизан отрядлары оеша башлый. Зөһрә шунда китәргә карар кыла. Ул отрядка килеп кушылганда, анда 60лап кеше була инде. Күбесе – Колчак, Семенов гаскәрләреннән, әсирлектән качкан солдатлар, авылларыннан ирек эзләп чыгып киткән яшьләр. Күпне күргән тәҗрибәле сугышчы, белемле кеше буларак, Зөһрәне отрядның комиссары итеп сайлыйлар. Отряд бер елга якын хәрәкәт итә һәм Кызыл Армия өчен шактый гына файдалы эшләр башкара. Колчак һәм Семенов тылындагы авылларда Совет власте урнаштыручылар да, якынлашып килүче Кызыл Армиягә азык-төлек белән ярдәм итүчеләр дә, качып китәргә теләүче байларның алтын-көмешләрен конфискацияләүчеләр дә шул партизаннар була. Мәсәлән, бер пот тирәсе алтын-көмешне нәкъ менә Зөһрә үзе саклый һәм, Омск Колчак гаскәрләреннән азат ителгәч, Совет хакимиятенә дә үзе илтеп тапшыра.

Күңелсез хәл

Зөһрә 1920 елда Казанга кайта. «Без Бристоль номерларында Галимҗан Ибраһимов, Әминә Мөхетдинова һәм башка иске дусларым белән бергә яши идек. 1921 елның мартында, ГПУдан килеп, мине кулга алдылар. Имеш, Сәхибгәрәй Сәетгалиевка атучыга наган биргәнмен икән. Мин тиешле җавабымны бирдем. Чөнки ул көнне юлда идем. Наганымны да Чистай милициясендә калдырган идем. Партизанлык документларымның барысын да күрсәттем», – дип тормышындагы күңелсез вакыйганы да язып калдырган ул.

Сәетгалиевчеләр Зөһрәгә барыбер кырын карыйлар. Ахыр чиктә, ул намуслы булуына ышанмаган кешеләр арасында эшли дә, яши дә алмый, күрәсең, Омскига китеп бара. Бер ел эшләгәннән соң Семипалатинскига күчәнә. Бу шәһәрләрдә аның белән бергә партизанлык иткән дуслары, көрәштәшләре исән була әле. 1927 елга кадәр ул Семипалатинск өлкәсендә хатын-кызлар хәрәкәтенә җитәкчелек итә, аларны яңа тормышка әзерли. Балалар яселәре оештыруда башлап йөри, чукрак-телсезләр мәктәбендә укыта. Өлкә район судында сәркатип булып та эшли. Хезмәт кенәгәсеннән күренгәнчә, аның 1932 елдан алып Татарстанның Мамадыш партия комитетында инструктор булып эшләгәне дә билгеле.

Зөһрә Алтынбаеваның Казанга яңадан кайчан әйләнеп кайтуы турында төгәл документлар сакланмаган. Ул Горький һәм Комлев урамнары чатында урнашкан сукыр-чукраклар мәктәбендә директор вазыйфасын башкара. 1943 елда (ае, көне билгеле түгел) аңа мәктәп янындагы коега слесарь карт төшкәнен, ләкин газга тончыгып, аңын югалтканын килеп әйтәләр. Зөһрә коега ташлана, картны күтәреп, өстәгеләр кулына тапшыра алган, әмма үзе, хәлсезләнеп, кире коега егылып, җан биргән.

Тәэминә апа Биктимирова әйтүенчә, архивтагы материаллар аның тормыш юлын тулысынча яктырта алмый. Әмма галимә аның кылган гамәлләрен бик югары бәяли. «Кеше бәхете өчен бу кыз бала нинди авырлыклар күрмәгән дә нинди рәхимсез рәнҗетелүләр кичермәгән. Ул кылган эшләрне эшләргә күбебезнең хәленнән килмәс иде. Искә алуыбыз аның рухына шатлык өстәсен», – диде ул.

БАТЫРЛЫК ЯЛ ИТМИ

Татарстан табибы Кара диңгездә суда баткан баланы үлемнән коткарып калган. Хәер, Сарман районының Җәлил бистәсе хастаханәсенең баш табиб вазыйфаларын башкаручы Евгений Окшин үзен герой дип санамый. Минем урында һәркем шулай эшләр иде, ди ул.

– Дүрт ел ял иткәнем юк иде. Быел уйлаштык та гаиләм белән Кырымның Феодосия шәһәренә ял итәргә барырга булдык. Бер көнне диңгездә су кергәндә, табиб кирәк, дип кычкырдылар. Шунда ук ярдәмгә йөгердем. Суга баткан малайны яр буена алып чыгып салганнар иде инде. Йөрәге туктаган, пульсы юк, клиник үлем кичергән, – дип искә ала Евгений. – Баланың гомерен саклап калу өчен барысын да эшләргә тырыштым. Сүз сабый гомере турында барганда җаваплылык тагын да арта. 15–20 минут тирәсе тырышкач, малайга «җан керде». Аннары аны «ашыгыч ярдәм» машинасы алып китте.

Яшәү белән үлем арасында калган улын күреп, әнисенең дә хәле начарая. Ханым аңын җуеп егыла.

– Мәскәүдән ял итәргә килгән 9 яшьлек Никита исемле малай булып чыкты ул. Алай тирәнгә дә кермәгән ул. Су астын күзәтә торган битлек кигән була. Сабыйның суда эпилепсия өянәге башлана. Мондый диагнозлы балага су астына чумарга һәм махсус битлек киярргә гомумән ярамый! Мин бу хакта аның әти-әнисенә дә аңлаттым. Диңгездәге бу хәл гомерлеккә сабак булсын иде, – ди Евгений Ошкин.

Якташыбызга Кырым Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисенең Рәхмәт хатын тапшырганнар. Ике көн элек кенә Җәлилгә кайтып җиткән табибка 20 ел дәвамында бик күп кешеләрнең гомерен саклап калырга туры килә. Әле ялга китәр алдыннан гына салкын тиюдән өзлегеп, тыны кысылган 6 айлык сабыйга да ярдәм иткән ул.

– Табибларның төп бурычы – кешеләрнең гомерен саклау. Шушы һөнәрне сайлагабыз икән, без аны намус белән үтәргә тиеш. Никитаның хәле уңайланды инде. Без аның әтиәнисе белән гел элемтәдә тордык. Кайтып китәр алдыннан, алар белән кабат күрешеп алдык. Рәхмәт әйттеләр. Тик мин аңа матур сүзләр ишетү түгел, ә бурычым шундый булганга, намусым шулай кушканга ярдәм иттем, – ди хатыны белән 4 малай тәрбияләүче Евгений.

Җәлил бистәсендә яшәүче танышларыма шалтыратып, Евгений Иванович турында сораша башлауга ук, аның бик тә тәҗрибәле табиб икәнен әйткәннәр иде. Ул берәүне дә кире бормый, кулдан килгәнчә кешеләргә ярдәм итеп яши икән. Җәлил халкы аңа бик рәхмәтле. Хәер, Евгений Ошкин үзе дә бер рәхмәтнең мең баладан коткарганын яхшы белә.

НУРЛЫ КЫЗ

Алабугада яшәүче 16 яшьлек Таңсылу Сибгаеваның бер кочак диагнозы бар. Тик кыз бу хакта уйламаска тырыша, матур итеп яшәп булганын башкаларга да күрсәтә. Аңа сокланмый да мөмкин түгел. Аның күңеле һәркемгә ачык. Үзен якын иткән кешене әллә кайдан сизә. Быел тугызынчы сыйныфка укырга бара.

– Кызымны җиде айдан таптым. Баштарак сәламәтлегендә тайпылышлар сизелмәде, табиблар да берни әйтмәде. Таңсылуга җиде ай чагында аның дөрес итеп утыра алмавын күреп алдык. Шуннан соң белгечләргә күрсәтергә булдык. Кат-кат тикшергәч, Казанга ук җибәрделәр. Кызыма ДЦП диагнозы куелды, – дип искә ала Эльвина. – Баштарак мин моңа ышанмадым да. Яхшыга өметләндем, йөреп китәр дип уйладым. Хәтта табиблар инвалидлык алырга чакыргач та, бармадык. Ул кәгазьләрне соңыннан гына рәсмиләштердек.

Ана күңеле медицина җиһазларыннан сизгеррәк булып чыга бу очракта. Таңсылуның хәле акрынлап яхшыра башлый. Тернәкләндерү курслары үтү бушка китмәгән. Кыз әкренләп хыялына таба атлый. Әйе, чынлап атлый! Ул инде хәзер инвалид арбасында гына утырып тормый. Әкренләп тотынып йөри дә башлаган. Әмма егылырмын дип куркып, күбрәк үрмәләп йөри икән. Әнисе аны мактап туя алмый. Кыз акрынлап мөстәкыйль тормышка өйрәнеп килә. Социаль челтәрләрдә дә актив ул. Аеруча авылны, аның кешеләрен ярата.

Әнисе Эльвина – үзе дә авырлык күргән, ятимлек ачысын кичергән кеше. 10 яшендә әнисез калуы, ә тагын 10 елдан әтисез калуы да аны сындырмый. Ул үзендә яшәр өчен көч таба. Кызы белән яңа сынаулар узарга туры килсә дә, авыр вакытта ире белән юллары аерылса да, язмышына ачу сакламый.

– Үз әтием китеп барса да, иремнең әтисе безне ялгыз калдырмады. Мин аны каената түгел, ә үз әтием дип кабул итәм. Таңсылуның хәле яхшырсын өчен көчен кызганмады. Ул оныгы өчен барысына да әзер: утка да, суга да керергә риза. Таңсылу өчен дип, пони сатып алды. Кызымны шунда утыртып йөртә. Ишегалды тулы хайван анда. Кызым эти белән гел бергә, – ди Эльвина.

Рәмзил абыйга да тормышта күпне күрергә туры килгән. Моннан 9 ел элек хатынсыз калган ул.

– Мин әтигә һәм иремнең туганы Фирүзә апага бик рәхмәтле, – ди Эльвина. – Таңсылу еш кына Казанга апасына да кунакка бара. Апа, бер дә авырсынмыйча, кызымны тәрбияли. Казанда тернәкләндерү узганда, хәтта икешәр ай аны үзе йөртә. Минем өчен бик зур ярдәм бу. Ничек инде рәхмәтле булмыйсың?!

Фирүзә апасы исә Таңсылуга рәхмәт әйтә.

– Таңсылуның авыруы безне берләштерде. Дөньяга күзләребез ачылды. Без моны Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән сынау дип кабул иттек. Әле ярый авырып уянда ятмый. Ничек итсә итә, тотынып йөрергә тырыша, – ди ул. – Без гел сеңлебез тирәсендә бөтереләбез. Булышасы, ярдәм итәсе килә. Тик кайчагында без Таңсылудан үзебез үрнәк алабыз әле. Көчле булырга өйрәнәбез. Үзеңне ничек бар – шулай яратсаң, тормыш ямьләнә икән. Әнә сеңлебез шулай итә. Ул беркайчан да күңелен төшерми. Елап та утырмый. Тормышны яратып яши.

Таңсылуның күзләре янып тора. Һәр кешегә елмаеп, яхшы кәеф өләшә. Үзенең авыру икәнен күптән оныткан инде ул. Янәшәсендә җанын ярып бирерлек якыннары булу аны тагын да нык итә. Мәктәпне тәмамлагач, бабасы янына авылга кайтырга хыяллана.

Коткарырмын дип уйлаган

Андый кеше башка юк. 59 яшьлек Ришат Галиевның якыннары әнә шулай ди. Хәзер инде «иде» дип тә өстиләр. Күрәчәктер, типсә, тимер өзәрдәй ир-ат канализация чокырына төшеп һәлак булды. Берничә көн элек Түбән Кама районының Каенлы авылында булган фаҗигадә өч кешенең гомере өзелде.

Ришат Галиев тумышы белән Балык Бистәсе районы Күгәрчен авылыннан. Якыннары аны бик тә кешелекле иде дип искә ала. «Тәртип» радиосы алып баручысы, журналист Гөлназ Миньязовага да чит кеше булмый ул.

– Апамның иренең абыйсы иде. Авылдашлар да булгач, без бик якын идек. Ришат абыйның китеп баруына күңел ышанмый. Бик авыр хәл, – ди Гөлназ.

Ришат абый авыл-районнарда канализациягә хезмәт күрсәтүче оешмада эшләгән. Бу юлы алар Каенлы авылындагы балалар бакчасына килгәннәр. Люкны ачуга, иң элек аның белән бергә килгән иптәше аска төшеп китә. Төшүгә үк егыла. Ришат абый аны өстән күреп тора. Ярдәмгә кешеләр чакыра, аннары үзе дә аска төшеп китә.

– Иптәшен коткармакчы булган инде. Аска төшүгә үк, ул да аңын югалтып егылган. Агуланырмын дип уйламаган инде. Хәер, кемгәдер ярдәм кирәк вакытта кайсыбыз үзен уйлый соң? Ришат абыйның ярдәмгә чакырганын ишетеп, яннарына ике ир-ат килеп җитә. Алар да бер-бер артлы чокырга төшә, – ди Гөлназ.

Тормышны яратып яшәгән ул. Хатыны Зөлидә апа белән бер кыз, бер ул үстергәннәр.

– Бик чибәр ир-ат иде. Алар дүрт ир туган үскәннәр. Бер абыйлары күп еллар элек вафат булды. Инде менә хәзер Ришат абыйсыз калдык. Бик үкенечле үлем бу. Ни генә әйтсәк тә, хатынын, балаларын юатыр сүзләр табып булмый. Әле бит яшисе дә яшисе иде үзенә. Мөгаен, тегендә дә яхшы күңелле кешеләр кирәктер. Йөрәк бик өзгәләнә. Ришат абый гаиләбез өчен үз кеше, якын кеше иде. Гел аралашып яшәдек. Гаиләсенә сабырлык бирсен, үзенең урыны оҗмахта булсын, – ди Гөлназ.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ФИРДҮС ГЫЙМАЛТДИНОВ:

«КИШТӘМДӘ ҮЗЕМ ЯЗГАН КИТАП БУЛУ ХЫЯЛЫМ ИДЕ»

Тарихи романнар чоры үтмәгән әле. Бөтенроссия дәүләт телерадиокомпаниясенең Татарстан филиалы җитәкчесе, журналист, язучы Фирдүс ГЫЙМАЛТДИНОВ белән сөйләшкәч, шундый фикергә киләсең. Ни өчен ул һәр язучы тарихи әсәр язып карарга тиеш дигән фикердә? Җитәкче булу иҗатка киртәме, әллә ярдәмме? Әдәбият нинди өлкәдә кытлык кичерә? Әдәби тел белән журналистика теле арасында аерма бармы? Әңгәмә – шулар хакында.

«Татар-информ»

:: «Буа» романы китап булып басылып чыкты. Күләмле әсәрләр язуда бу – сезнең дебют, үзегез нәтиҗәсеннән канәгатьме?

– Үз китабыңны беренче тапкыр кулга алу – бәхетле мизгелләрнең берсе. Бу инде тапталган фикердер, әмма аны башкача аңлатып булмый. Киштәмдә үзем язган китап булу минем хыялым иде. Менә шул хыял чынга ашты. Әмма басылган әсәрне – журналист язмасымы ул, әдәби әсәрме – яңабаштан укып чыккач, башкача кабул ителә. Мин дә яңадан укып чыккач, хәзер үзгәчәрәк язган булыр идем, дип уйладым. Кайсыдыр мизгелләргә урын күбрәк бирелгән кебек, кайбер укучылар исә төп геройларның фаҗигале рәвештә вафат булуын яратып бетермәде. «Нигъ Таһир исән калды, нишләп ул җәзасын алмады, ә ике бертуган – мулла белән энекәше вафат булдылар?» – дип сораучылар булды. Миңа калса, тормышта да шулай. Адәм баласы Җир йөзендә яшәгәндә явызлык өчен һәрвакытта да җәзасын алмый, әмма барыбер җәза бирелә торган урын бар.

:: Тимер юл салу тарихы белән кызыксыну кайчан башланды? Сезнең туган авылыгыз да бит әлеге юл өстендә утыра.

– Югары Лашчы авылы Лашчы станциясеннән аз гына читтәрәк урнашкан, шулай да без балачактан тимер юл салу вакыйгасына бәйле истәлекләрне тыңлап үстек. Әбиләр сөйләвенчә, 1941 елда алар башта Казан каймасы төзелешендә эшлиләр. Ә инде 1942 елда, фашистларның Казанга кадәр килеп җитә алмаячагы аңлашылгач, ул эшне ташлыйлар һәм тимер юл төзелешенә керешәләр. Менә шушы тимер юлга быел 80 ел була. Бу төзелештә катнашкан кайбер әсир немецлар безнең якларда төпләнеп тә кала. Мин әле бу теманы тулаем ачыклап бетермәдем, әмма өйрәнергә җыенам. Әйтик, Килдураз якларында тун тегүче немец бар иде, дип сөйләделәр. Чөнки һөнәргә оста немецларны, эш беткәч, колхоз-совхозлар үзләренә сорап алып та калганнар. Болар – сугышта әсирлеккә эләгүчеләр түгел, бәлки Саратов якларында Әби патша вакытында җир биреп, Россиягә чакырылган һәм үз республикаларын төзегән немецлар. Бөек Ватан сугышы башлангач, аларны ул җирләрдән Казахстанга, Урал аръягына сөрәләр. Алардан оешкан хезмәт армиясе мең чакрымга сузылган, Зөя станциясеннән Сталинградка кадәрге өлешендә эшли. Сталинградтан арырак аларны җибәрмиләр, чөнки качып китәрләр дип куркалар. Алар белән бергә Апас, Буа, Чүпрәле, Кайбыч, Кама Тамагы, Тәтеш, Яшел Үзән һәм Чувашиянең Татариягә якын районнарыннан кешеләр эшли. Районнарга көнгә 500 кеше җибәрергә дигән план куела. Ирләр сугышта, авыр хезмәткә хатын-кыз, әби-чәби, гарип-гораба, карткоры җибәрелә. Алар җилкәсендә биш ай эчендә шушы юл салына.

:: Канлы тир тамган һәм күпме гомерне алып киткән юл...

– Тимер юлның шушы участогы начальнигы булып Илгиз Фәйзир улы Нигъмәтуллин эшләгән. Ул – хәзер туган якны өйрәнүче тарихчы, «Путь к Победе» дигән китап та чыгарды. Әлеге китапта Илгиз ага төзелешкә кагылышлы бик күп тарихи документларны туплап биргән. Партия утырышлары документлары да, кемнең нәрсә өчен атып үтерелгәне, качучылар турында мәгълүматлар – анда бар да бар. Мин дә шушы китапка таяндым. Илгиз Фәйзировичка бик рәхмәтлемен, ул документлар гына туплап калмый, тимер юл музееп да оештыра, үз куллары белән землянка макетларын да ясый, бик бай материал туплый. Ул миңа тимер юл полотносын төзекләндергән вакытта бик күп сөякләр чыгуы турында да сөйләде. Күрәсең, үлеп калган немецларны шунда ук күмгәннәрдер. Кулдан салынган юл дисәк тә дөрес булыр, чөнки бөтен участокка нибары ике трактор бирелә, алары да эшли торган булмый. Калганы арба, көрәк, кәйлә ярдәмендә эшләнә. Хәтта атлар да сугышка озатыла. Бу – коточкыч зур хезмәт, аның әле бик күп сәхифәләрен өйрәнергә кирәк. Ни кызганыч, без бу вакыйганы күреп бетермибез кебек тоела.

:: Романда реаль прототиплар бармы?

– Конкрет прототиплар юк, анысы хак. Ләкин мин ул чорга кагылышлы әдәбиятны шактый укыдым, нәтиҗәдә шул образлар туды. Хәмидулла мулла артык идеаль дип тә уйларга мөмкин. Тормышта бит андый кешеләр бар. XX гасыр башы әдәбиятында сурәтләнгән «сәдака караклары» дигән образдан бәлки читләшергә вакыттыр инде. Мәхәлләне кайгыртучы, мәдрәсәләр тотучы, милләтнең нигезен саклаучы муллалар да булган һәм минем Хәмидулла мулла шундыйлардан.

:: «Буа» конкрет җирлеккә багышланган әсәрме?

– Мин романга баш исемне төрлечә куеп карадым. Үзегез дә беләсез инде, мәкаләне язуга караганда баш исемне табу авыр. Бу исем Ркаил Зәйдулла фатихасы белән куелды. Уңышлы килеп чыкты дип уйлыйм.

:: Ркаил Зәйдулла, әйдә яз инде дип, кыстап алып керде әдәбиятка, дидегез бер әңгәмәдә. Бер караганда, бу әйбәт, икенче яктан, әдәбиятта ирләр кытлыгы икәнлегенә дә ишарә.

– Ә ул аны миңа беренче очрашкач та әйтте. Мин – шагыйрь, прозага кытлык булганга, язарга мәҗбүрмен, дигән иде. Бу – 1998 нче еллар. Бу бик уйландыра. Ә икенче яктан, ир-ат язучылар юк дип тә әйтеп булмый бит. Бөтен милләт күләмендә ул шулай санаулы була инде.

:: Әлеге романда игътибарга лаек төп өч факт.

– Бердән, кешеләр язмышы аша илебезнең тарихын күзаллап була. Икенчедән, тарихи фактлар белән танышырга мөмкин. Өченчедән, китапны укып чыгып, әйбәт булганмы, начармы – миңа бәя бирергә була.

:: Фирдүс, ике роман яздыгыз, икесе дә тарихи темага. «Урда ханы Үзбәк», гомумән, ерак тарихка багышланган. Ә бездә ул катламнарга алынучылар бик аз. Фәүзия Бәйрәмова, Ольга Иванова бар. Элек Нурихан ага Фәттах, Мөсәгыйт Хәбибуллин бар иде. Тарихи роман язучылар әлеге әсәргә карата үз фикерен әйттеме?

– Бу роман белән алар әле танышмаган, ә мин алдан барып сорашып йөрергә оялдым. Тарихи жанрда иҗат итүче олпат язучыларыбыз хәзер дә бар: Вахит Имамов, Марат Әмирханов, Ркаил Зәйдулла… Бу исемлек зур дип уйлыйм. Гомумән, теләсә кайсы язучы тарих белән кызыксынырга тиеш инде ул, бигрәк тә үзенең халкына, милләтенә, дәүләтенә кагылышлы тарих белән. Мин үзем дә «Урда ханы Үзбәк»нең китап булып чыгуын көтәм. Ул башта «Казан утлары» журналында басылачак. Аннан соң бәя бирерләр инде. Һәрхәлдә, галим Дания апа Заһидуллина бәясен бирде. Ул артык мактамаган да, салып таптамаган да. Шул ук вакытта «классик рухтагы тарихи роман» дигән минем күңелемә сары май булып ятты. Мин чыннан да фантасмагорияләргә бирелмичә, үзем өйрәнә алган дәрәҗәдәге тарихи сукмактан барырга тырыштым. Барып чыкканмы ул, юкмы – анысын белгечләр әйтер.

:: Әдәбиятта тарихи жанр ни хәлдә?

– Дания апа бәяләмәсенә әйләнеп кайтсак, ул тарихи романнар чоры үтте дигән фикердә. Шул ук вакытта, әйтик, рус әдәбиятын алсак, бу жанрда актив иҗат итәләр.

:: Андый романнар буенча төшерелгән фильмнар да кызыклы бит әле. Әйтик, «Великолепный век»ны бөтен дөнья карады.

– «Урда ханы Үзбәк»не язганда бәлкем әле ул фильмның да йогынтысы булгандыр. Романда хатын-кызларның ир-атка йогынтысы ни дәрәҗәдә булуы, әйтик, ханның Тайдулла хатынга булган чиксез мәхәббәте дәүләт эшләренә дә йогынты ясавы ассызыклап әйтелә.

:: Икенче проблема да бар бит әле. Тарихи әсәр язганда таяныч булырлык язма чыганаклар бик аз.

– Шактый эзләнергә туры килде. Тарихи әдәбият та укылды. Менә аларның бер өлеше монда (китап киштәсенә күрсәтә. – **Ред.**). Бертольд Шпулер әсәрләре, Фәннәр академиясе чыгарган «Золотоордынское обозрение» журналы, төрле чыганакларда басылган фәнни мәкаләләр – шуларны өйрәнеп ниндидер мозаика җыеп була. Әйтик, Шпулер китабы хронологиягә бай, ә мәкаләләрдән Алтын Урдада кыз ярәшү тәртибен, кораллану үрнәген өйрәнеп була. Шулар аша сюжет җыела. Эзләнүм дигән кеше таба.

> Үткән тарих җентекләп өйрәнелмәгән әле. Ә бит бик күп милләтләр ул тарихны үзенеке итәргә омтыла. Бигрәк тә Урта Азия илләре үзләренә байләргә тырыша. Шуңа бу юнәлештә актив эшләргә тиешбез. Бу җәһәттән әдәбият та ярдәм итә ала. Әйтик, «Спартак» әсәре язылмаган булса, гладиаторлар фаҗигасе ул дәрәҗәдә халыкка барып ирешмәгән булыр иде.

:: Журналист барыбер журналист булып кала, аның теле әдәбиятка бармый дигән фикер дә бар бит әле.

– Минем телем камил түгел, ничек бар – шулай яздым. Үзенчәлекледер. Ләкин журналист теле белән әдәби тел икесе ике төрле дигән фикер белән мин килешмим.

:: Шул ук вакытта урам теле белән язарга өндәүчеләр дә бар.
– Мин моңа тискәре карыйм. Мәсәлән, безнең якта өйне – ызба, болдырны, крыльцоны бозып, криса дип әйтәләр. Мин бит аны экран сөйләменә дә, әдәби әсәремә дә чыгара алмыйм. Журналистика әдәби телдә булырга тиеш. Әлбәттә, аның аңлаешлы булуы шарт. Сөйләмеңне яки язмаңны фарсы алынмалары белән тутырсаң, аны аңлау кыен булачак. Җыеп әйткәндә, матбугатта, радио-телевидениедә, интернет басмаларда калыпка салынган матур, аңлаешлы әдәби телебез булырга тиеш. Бу – бәхәссез. Бөтен нәрсәне дә гадиләштерергә ярамый. Гадиләштерү нәрсә ул? Урыс сүзләрен күбрәк кыстырумы, сүгенү сүзләрен кертүме? Әйе, тел үзгәрүчән, ләкин аның хәзерге чорда үз кануннары бар. Язучы да, журналист та шул кануннарга нигезләнеп яза.

:: Ә ул тел хәзер нинди хәлдә соң? Кайчак, радио тыңлагач, бик моңсу булып китә...
– Минем дә моңайган вакытлар була. Калька бик күп хәзер. Телнең чисталыгы мәсьәләсендә проблема һәрвакыт булган, шуңа бу юнәлештә эшләүдән туктамаска кирәк. Дикторлар белән дә, ди-джейлар белән дә эшләргә, осталыкны чарларга кирәк.

:: Җитәкче кешегә иҗат нәрсә бирә?
– Ирек бирә. Син үзең язган геройларның тормышы белән яшисең, шул хыялый дөньяга кереп китәсең. Җитәкченең тормышы бал да май, кәнәфиендә әмер биреп кенә утыра, дип уйлыйлар бит бездә. Алай түгел икән. Үзем дә җитәкче булгач кына аңладым. Ә иҗат – тәрәзәне ачып, бүлмәңә саф һава кертү шикелле. Аннан соң ул газап та. Ул сиңа ябыша да җибәрми. Яздың да, илтеп тапшырып, премиясен алдың гына түгел.

:: Тел комиссиясе игълан иткән әдәби конкурс булмаса, язар идегезме?
– Әлбәттә. Бәлки ул озаграк туар иде. Чөнки конкурсның вакыт чикләре иҗатны тизләтә. Әмма мин барыбер конкурска җиңү өчен язмадым. Иң беренче кеше күңелендә хыял булырга тиеш. Мин балачактан китап яраттым, кечкенәдән үземнең китабымны чыгарасым килде. Бәләкәй чакта абыйны битәрли-битәрли китапханәче булып та уйнарга ярата идем. Чөнки авыл китапханәсенә яңа китапларны әти алып кайта. Ул китаплар башта безнең өйгә керә. Тәмле кәгазь, буяу исе аңкып торган китаплар гел ымсындырып торды.

:: Сезнең бренд тавышмы, романмы хәзер?
– Тавыш дип инде... Алай түгел ул. Матур тавышлар бар һәм күп.

«Татар җыры» фестивале башланганда, 2000 нче елларда аларның роликларын яңгыратуларын үтенделәр. Ул вакытта «Барс-медиа»ның күтәрелеп киткән чагы, шуңа бөтен җирдән, «ТНВ»дан да, радиодан да шул ролик әйләнде. Берәү, үтүкне кабызсам, аннан да син кычкыра башларсың дип куркам, дигән иде хәтта. Мин тавышны бренд дип санамыйм. Кирәк икән, хәзер дә текстларны укыйм. Мактанып әйтим әле: «Татарстан» радиосында Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» әсәре буенча радиоспектакль яздырдык. Мәртәбәле артистлар белән беррәттән, без – фәкыйрегез дә бер кечкенә генә рольне башкарды. Ходай биргән тавыш, куллансыннар, беркайчан да каршы килгәнем юк. Кирәк чакта укыйм.

:: Тавышның хәлиткеч мизгелдә ярдәм иткәне бармы?
– Телевидениегә кереп китүем дә тавыштан башланган иде. Ул чакта белмим бит үземнең тавышның ниндидер үзенчәлеге булуын. «Дулкын» радиосында эшләгәндә, Илфат Фәйзрахманов телефоннан минем тавышны ишетеп, шул тавыш буенча минем образымны тудырган икән. Килгәч, тавыш буенча туган образның чынбарлыкка туры килмәвен күрделәр. Көрәшчеләр кебек олпат гәүдәле кеше көткәннәр, күрәсең, ә монда ишектән ябык кына, зур күзлек кигән малай күренгән. Чыннан да мине тавышым йөртте. Кайвакыт: «Син тавышыңны куйдыңмы?» – дип тә сорыйлар. Юк, куймадым да, тавыш белән шөгыльләнмәдем дә. Мин үземнең яздырылган тавышымны тыңларга яратмыйм, ул миңа ошамый, ямьсез кебек тоела. Габделфәт Сафин гына шалтырата иде дә: «Фирдүс, мондый матур тавыш республикада бары тик синдә һәм миндә генә бар», – дип әйтә иде. Бусы салпы якка салам кыстыру инде, аңа реклама яздырырга кирәк иде.

:: Яңа әсәр языламы?
– Башта бер идея бар, әмма тотынмаган әле. Алмагачка да ял кирәк булган шикелле, миңа да ял кирәк икән. Тел белгече, галим Илдар абый Низамов, илһам килгәнне диванга кырын ятып көтәргә кирәкми, көн дә язарга кирәк, дип әйтә иде. Әмма ул кагыйдә миндә эшләми. Кайчак языла башлаган әйберне дә ташлап торырга кирәк. Мәсәлән, «Буа»ны мин дүрт ел яздым. Башладым, ташладым, чын мәгънәсендә арыдым мин аннан. Газапламаса, әсәр тумый торгандыр ул. Яңа язылачак әсәр исә күпмедер дәрәҗәдә тарихи, күпмедер дәрәҗәдә тарихи да түгел. Чөнки безнең үзебезнең чор да бар бит әле.

> Без – җитмешенче, сиксәненче елгылар – балачактан нинди зур илдә яшибез, дип горурланып үстек. Октябрят булдык, пионер булдык. Аннары комсомолы да, иле дә бетте. Безнең буынны балачактан алдап үстергәннәр булып чыга бит инде.

Ленин бабай дип җырлатып үстерделәр дә, аннары постаменттан бәреп төшерделәр. Аннан әчкечелек көчәйде, эшсезлек артты, колхозлар таралды. Шуңа безнең буын вәкилләре арасында үз теләге белән якты дөньяны ташлап китүчеләр дә бик күп. Бу – тулы бер буын фаҗигасе. Ул хакта да язарга кирәк. Җыеп әйткәндә, язарлык әйберләр күп. Шуңа күрә күңелендә булган милләттәшләргә, языгыз, дип әйтер идем.

:: Китап укучы калса...
– Китап укучысын, гомумән, киң даирә дип әйтеп булмыйдыр. Шул ук авылда да укытучылар, мәдәният хезмәткәрләре, дин әһелләре китапка тартылучан. Ул даирә, минемчә, сакланыр. Телне ничек саклап калырга дигәндә, бу – минем өчен бик катлаулы сорау һәм мин төгәл рецептын да белмим. Миңа калса, һәрбер адым файдалы. Монда ике икең дүрт дигән җавап була алмый. Шуңа күрә интернетта да, газета-журналларда да, радио-телевидениедә, элмә такталарда – телебезгә йогынтысы булган һәрбер эш файдалы. Бәйге игълан ителмәсә, язар идеңме, дигән сорауга әйләнеп кайтсак, ул, әлбәттә, этәргеч булды. Бу конкурс әдәбиятка игътибарны күпмедер дәрәҗәдә уятты, потенциалның зур икәнен күрсәтте. Ләкин ялкаулык дигәне дә бар. Күп жанрларны җанландырып җибәрәсе бар әле. Ә аның өчен эшләргә, язарга кирәк. Бер җиңмәсәң, икенче конкурста җиңәргә мөмкин. Бераз оялып эшләргә кирәк инде аны. Бер әйбер яздым да дөньяны коткардым, дип йөрү шулай ук дөрес түгел. Кеше синнән алга таба да әсәр көтә.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ҖӘНГИЗ ЙӨРҮК

КЕШЕЛӘРНЕ ЯЛГЫЗ КАЛДЫРМАГЫЗ

Танылган тәрҗемәче Кыям абый Миңлебаев, исән чагында, төрек язучылары хикәяләрен туплап, китап чыгарырга теләгән иде. Бу әсәрне тәрҗемә итәргә миңа тапшыруы да шул нияттән булды. Кызганыч ки, теләге тормышка ашмый калды. Бакыйлыкка күчкәненә сентябрь башында 17 ел тула. Шушы хикәя остазымны искә алуның бер чарасы булсын иде.

Фәния ФӘИЗОВА

Автомобильнең ишеге ачылгач, төн карасын ертып, зәгыйфь кенә яктылык сирпелде. Стаканнардагы чәйне түкмәскә тырыша-тырыша, малай подносны машинада утыручыларга сузды.

– Молодец, Мәхмүт! – диде арткы утыргычтагысы. – Һәрвакыттагыча, капкайнарны китергәнсең.

Сөйкемле генә, сипкелле малай шатланып елмаеп җибәрде.

– Кер тизрәк, туңарсың йә, – диде теге кеше.

Малай ялт кына машинага кереп утырды. Алда тагын берәү – ягымлы карашлы күзлекле яшь кеше бар иде.

– Соңга каласың дип курыктык, борчыла да башлаган идек инде. Радиодагы тапшыру бара микән әле?..

Ул, радиоалгычны боргалап, кирәкле станцияне тотты: балалар хоры җырлый иде.

– Менә бәла, – дип куйды ул, канәгатьсезлек белән, – әкият беткән бит...

уятмаска кушкан. Ул безгә матур-матур уенчыклар алып кайтачак... Хакки абый, «мәңгелек» – нәрсә дигән сүз ул?

Ир кеше сискәнеп китте:

– Аңламадым, ни турында сорыйсың?

– Мәңгелек – нәрсә ул, дим. Минем абзый әнигә һәвакыт: «Ирең мәңгелеккә китте», – ди. Мин килеп кергәч, туктап кала, сөйләми.

– Ә-ә-ә, – диде Хакки, – бик ерак юлга чыгып киткәнгә күрә шулай әйтә инде ул. Әтиең киткәнгә күп вакыт үтте бит.

– Җиде ай «бик озак» дигәнне аңлатамыни, Хакки абый?

– Әйе, шулай, – диде ир кеше, ашыгып. – Көннәр, айлар уза, ел фасыллары да алмашына. Менә шул «бик озак» була инде.

– Әтием киткәндә җылы иде әле, ә хәзер суытты. Салкын чакта кешеләр кайнар чәй яки салеп (күке яше үсемлегеннән ясала торан кайнар эчемлек. – **Ф.Ф.**) эчәләр. Хәзер җәй булса, туңдырма ашар идек, әйе бит, Шинаси абый?

– Ярар инде, – дип юатты арттагысы, – дүрт көннән тагын була ул. Анысында Мостафаны да алып килерсең.

Мәхмүт аскы иренен тешләп куйды, аның сипкелле йөзендә үкенеч төсмере күренеп китте.

– Мостафа йоклый шул. Йоклама, дип әйтеп тордым да бит, изрәп киткән.

Күзлекле егет яратып елмайды:

– Кечкенә бит әле ул. Биш яшьтә йокламый түзү кыен инде. Ярый ла син зур үскәнсең.

– Әни дә шулай ди. – Малай, җирәнеп, иреннәрен бөрештерде. – Ә кичә, Шинаси абый, караватында балык та тоткан иде әле ул.

Көлеп җибәрмәс өчен, күзлекле егет бер-ике кат йөткереп куярга мәҗбүр булды. Иптәше, йөзен Мәхмүттән яшереп, кулъяулыгы белән тырыша-тырыша борынын ышкый иде. Беренчесе:

– Әтиегез сәяхәттән кайткач, сезне танымас та: шулкадәр үсеп киттегез. Бигрәк тә син, Мәхмүт. Мәктәпкә йөрисең, билгеләрең дә әйбәт. И-и сөенер инде, әйе бит? – дип сорады.

Бер ноктага текәлгән килеш, малай:

– Белмим шул, – дип җавап бирде. – Әни әйтеп торды әле: нәкъ җиде ай үткән икән...

Аннары кинәт:

– Син минем әтине белә идеңме, Шинаси абый? – дип сорап куйды. – Ә син, Хакки абый?

Хакки никтер пышылдауга күчеп, әкрен генә:

– Фотосын гына күргәнем бар, – диде.
– Ишетүен күп ишеттем аның турында.

– Танышкач, әтием сезгә бик ошар! Дуслашып та китәрсез әле...

Ирләр сүзсез генә бер-берсенә карашып алдылар. Сабый ихласлыгыннан да гүзәлрәк ни бар икән дөньяда? Икесе дә шуны уйлагандай, ризалашып баш кактылар.

– Әти бик иртә чыгып киткән. Мостафа белән без йоклап калганбыз. Әнигә безне

– Әлбәттә, Мәхмүт, – ди күзлекле егет.

– Шинаси абый, ә сез җәй көне дә килерсезме?

– Килербез, мәңгелек юл беткәнче килеп йөрербез...

– Син нәрсә? – дип пышылдады Хакки һәм малай күрмәгәндә генә иптәшенә төртеп куйды.

Шулчак моннан җиде ай элек булган хәлләр ихтыярсыздан Шинасиның исенә төште.

Эссе июнь иртәсе иде. Сәгать ун. Хуҗасы аңа ике папка тоттырды. «Атна ахырына кадәр шушы «эш»ләрне тәртипкә китерергә кирәк», – диде ул. Шинаси папкаларны алып чыгарга гына җыенган иде, хуҗа яңадан туктатты: «Ул эшләрне калдырып тор әле. Җаваплырак эш кушам мин сиңа. Әйбәт башкарып чыга алсаң, күтәрермен үзеңне. Бу эш белән Хакки шөгыльләнә дә инде. Бергә-бергә җайлырак булыр: кирәк булганда икәү эшләрсез, кирәк булса чиратлашырсыз. Тик ашыгычлык белән эшне бозып ташлый күрмәгез, зирәклек кирәк монда». Хуҗа, өстәл тартмасыннан газета кисәге алып, Шинасига сузды.

– Беләм, беләм, – диде тегесе, текстка күз йөртеп чыккач. – Тик безгә нәрсә эшләргә соң?

– Ничек инде «нәрсә эшләргә»? Шуны да аңламыйсыңмыни? Кеше чит илгә качкан, ә аның хатыны ике баласы белән монда калган. Аларын да качырмас өчен тырышырга кирәк. Боерык бик катгый. Бер генә минутка да күздән җуймагыз. Һәркөнне миңа хәбәр итә торган булырсыз. Өйләрен күзәтергә. Кемнәр килә, нәрсә эшлиләр – барысын да белеп торырга. Әнә сезгә соры машина. Бәлки, яшерен оешманың эзенә төшә алырбыз. Җепнең очын эләктерәсе иде. Сез әле яшь, эшнең җаен беләсез, белемегез җитәрлек. Мин сезгә ышанам!

Ахыры бар >

КОТЛЫЙБЫЗ!

Байлар Сабасында яшәп гомер итүче **ШАЙМАРДАНОВ Фәрит Әмин улы** һәм **Сиринә Харрас кызының** туган көннәре.

Кадерле әтиебез, әниебез, дәү әтиебез, дәү әниебез! Сезне 75 яшьлек юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйбыз.

Без сезгә саулык-сәламәтлек, озын гомер, күңел тынычлыгы, бәхетнең зурысын, шатлыкларның олысын телибез. Балаларның, оныкларның игелеген күреп, бергә тигезлектә, пар канатлы булып, бер-берегезгә терәк булып, озын-озак еллар яшәргә насыйп булсын.

Җирдә кояш нуры балкыгандай,
Сез балкыйсыз безнең күңелдә.
Тормышыбыз сезнең белән матур –
Рәхмәтлебез сезгә гомергә!

Матур гомер бәйрәмегез белән сезне, әтиебез, әниебез, дәү әтиебез, дәү әниебез!

Иң изге теләкләр белән, сезне яратып, балаларыгыз ГӨЛНАРА – МАНСУР, АЙГӨЛ – ДИНАР, оныкларыгыз ЛИЛИЯ, АЛИНӘ, ЗӘЛФИЯ

Әз-мәз мәзәк

* * *

Кассада торганда, ташкабак сатып алган кешене җәлләдем. Бер туганы да, дусты да юктыр инде бичараның.

* * *

Әгәр дә ике көн яңгыр яуганнан соң матур итеп кояш чыга һәм көн җылына икән, мөгаен, бүген дүшәмбедер.

* * *

Сәер хәл, әмма хезмәт хакы никадәр кечкенә булса, аны эшләп алу да шулкадәр авыррак.

* * *

– Мин – кошлар тану буенча белгеч.
– Әнә тегендә агач башында нәрсә утыра?
– Таныдым. Кош.

* * *

Минем шәһәрдә яхшы белгечне тану бик җиңел: әгәр ул минем шәһәрдән качкан икән, димәк, ул – яхшы белгеч.

* * *

Атнаның иң тыныч көне – чәршәмбе. Ул атна башындагы план төзүләрдән һәм шул планнарның атна ахырында чәлпәрәмә килүеннән бер үк ераклыкта урнашкан.

* * *

Яхшы логопед турында аның клиентлары бер генә начар сүз дә әйтә алмый.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: октябрь, Салиха, тарак, Таҗетдинов, әтәч, Дим, елга, лапас, ирис, Динә, кире, НЛО, пәрәмәч, кишер, зая, Вася, Лима, Җәмилә, Ганс, Нәрсә, Арча, Ми, Гаяз, Фәндәс, Наил, Урам, Лерон, исита, Артём, Икарус, Обляй, афәт, кайнар.

Вертикаль: Фәтхетдинов, Африка, аҗаган, Ксения, Асаф, Әлфия, Замирә, кат, тут, келәт, ас, яки, Рим, Мин, ара, Рио, Ризалә, Вәсилә, Әрмәнстан, маяк, си, Мәликә, Филмор, ат, Час, Шәле, лак, Раяз, ир, Данис, радио, Харис, Нияз, ак, Нефтеюганск.

Беләсең килсә...

1 «Хәзинә» романын кем язган?

а) Мөхәммәт Мәһдиев;
б) Гомәр Бәширов;
в) Гариф Ахунов.

2 Җырчы Винарис Ильегетнең чын исеме:

а) Блюхер;
б) Блехер;
в) Блёхер.

3 «Нәрсә ул сидерофобия?

а) йоклап китә алмам дип курку;
б) караңгылыктан курку;
в) һавадагы йолдызлардан курку.

4 Израильдә ул бик зур булып үскән. Аның авырлыгы 5 килограмм 265 грамм була. Дөньяда бу рекордны әле бәрүче юк. Сүз нәрсә турында?

а) алма;
б) лимон;
в) кыяр.

Җаваплар: 1. в); 2. б); 3. в); 4. б).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15838 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 316

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+